**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы территориясендә аучылык биләмәләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы территориясендә аучылык биләмәләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасын актуальләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә аучылык биләмәләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасын раслау турында» 2015 елның 3 октябрендәге ПУ-968 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 19 маендагы ПУ-381 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы территориясендә аучылык биләмәләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасына, аны кушымтада бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 21 декабрь
№ ПУ-979

Татарстан Республикасы
Президентының
2021елның « 21 » декабрендәге
ПУ-979 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы территориясендә аучылык биләмәләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасы**

## 1. Кереш өлеш

Аучылык хуҗалыгы Татарстан Республикасы икътисадының да, Россия Федерациясе икътисадының да мөһим өлеше булып тора. Аучылык биләмәләренең дала, урман, су һәм сазлык категорияләре булу Татарстан Республикасында ландшафт төрлелегенә китерә. Табигый-территориаль үзенчәлекләргә бәйле рәвештә, республикада ау өчен хайваннар дөньясының шактый бай һәм төрле булуы күзәтелә. Аучылык биләмәләрен дөрес оештырган очракта гына аучылык ресурсларын нәтиҗәле файдаланырга мөмкин.

«Ау турында һәм аучылык ресурсларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2009 елның 24 июлендәге ФЗ-209 номерлы Федераль закон (алга таба – «Ау турында» Закон) нигезендә аучылык өлкәсендә планлаштыру һәм аучылык ресурсларын саклау максатында аучылык ресурсларын нәтиҗәле файдалануны һәм саклауны тәэмин итүгә һәм Россия Федерациясе субъекты территориясендә аучылык хуҗалыгы өлкәсендә төрле эшләр башкаруга юнәлтелгән территориаль аучылык хуҗалыгы оештырыла. Аучылык биләмәләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасы территориаль аучылык оештыру нигезләнгән документ булып тора. Россия Федерациясе субъекты территориясендә аучылык биләмәләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасын төзү тәртибе һәм Россия Федерациясе субъекты территориясендә аучылык биләмәләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасы структурасына һәм составына таләпләр Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Россия Федерациясе субъекты территориясендә аучылык биләмәләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасын төзү тәртибе һәм Россия Федерациясе субъекты территориясендә аучылык биләмәләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасы структурасына һәм составына таләпләр турында» 2010 елның 31 августындагы 335 номерлы карары белән расланды. Әлеге норматив таләпләрне үтәү максатында Татарстан Республикасында аучылыкны булдыру эшләрен уздыру оештырылды, нәтиҗәдә Татарстан Республикасы территориясендә аучылык биләмәләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасы эшләнде.

Татарстан Республикасы территориясендә аучылык биләмәләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасы аучылык өлкәсендә озак вакытка исәпләнгән төбәк сәясәте формалаштыру, аучылык ресурсларын аларның күптөрлелеген тәэмин итү һәм санын аларның күпләп үрчүе өчен кирәкле дәрәҗәдә тоту, аларның яшәү тирәлеген саклау, аучылык хуҗалыгын комплеслы алып баруны икътисадый һәм социаль яктан акланырлык дәрәҗәсенә җиткерү, аның структурасын камилләштерү, аучылык ресурсларыннан файдаланучы хуҗалык субъектларын аучылык хуҗалыгы эшчәнлегенең социаль-икътисадый һәм экологик шартларына җайлаштыру, аучылык хуҗалыгы өлкәсендә алып барыла торган эш төрләрен башкару белән бәйле мәсьәләләрне нәтиҗәле хәл итүне тәэмин итүче чаралар комплексын гамәлгә ашыру өчен эшләнде.

## 2. Татарстан Республикасының физик-географик сыйфатламасы

### 2.1. Татарстан Республикасының физик-географик урнашуы

Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең Европа өлешендә, Идел һәм Кама елгалары кушылган җирдә урнашкан.

Административ яктан Татарстан Республикасы Идел буе федераль округына керә. Республика Россия Федерациясенең сигез субъекты белән чиктәш: көнбатышта һәм төньяк-көнбатышта – Чувашстан Республикасы һәм Марий-Эл Республикасы белән, төньякта – Киров өлкәсе һәм Удмуртия Республикасы белән, көнчыгышта һәм көньяк-көнчыгышта – Оренбург өлкәсе һәм Башкортостан Республикасы белән, көньякта – Самара һәм Ульяновск өлкәләре белән. Чикләр нык борылмалы һәм сынык сызык рәвешендә булып, табигать булдырган нинди дә булса чикләр белән бәйләнмәгән. Зур аралыкта Ык елгасы буйлап барган Башкортостан белән чик кенә искәрмә булып тора.

### 2.2. Татарстан Республикасы территориясендә климат шартлары

Татарстан Республикасы территориясенең климаты – уртача континенталь, җәе – җылы, кышы – уртача салкын.

Татарстан Республикасы территориясенең климатын тасвирлаганда, аның температур режимын сыйфатларга кирәк. Моның өчен һаваның айлык һәм еллык уртача температурасы күрсәткечләре кулланыла. Елның иң җылы ае – июль (+18…+20°С), иң салкыны – гыйнвар (−13…−14°С). Бөтен Татарстан Республикасы территориясе буенча берничә еллык уртача температура бүленеше күрсәткечләре уңай һәм төньяк-көнбатышта (Арча шәһәре, 3,4°С) һәм төньяк-көнчыгышта (Минзәлә шәһәре, 3,3°С) түбәнрәк күрсәткечләр күзәтелә. Шул ук вакытта көнбатышта (Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, 4,0°С), көньяк-көнбатышта (Иске Чүпрәле, 3,9°С) һәм Казанда (4,1°С) ул шактый югары. Татарстан Республикасы территориясе буенча 1966–2004 еллардагы күпьеллык күзәтүләрдән тупланган

мәгълүматлар буенча һаваның еллык уртача үзгәрү диапазоны 0,1 градустан (Минзәлә шәһәре, 1969) 6,3 градуска кадәр (Казан шәһәре,1995) тәшкил итә. Төбәк территориясендә температура кыры бердәй таралган. Иң түбән температура – 44...−48°С (1942 елда Казан шәһәрендә −46,8 °С) тәшкил итә. Иң югары температура Цельсий шкаласы буенча +37…+42 градуска җитә.

Ел әйләнәсендә һава температурасы башта акрынлап, ә аннары шактый тиз түбәнәя, һәм ноябрь аенда уртача күрсәткечләр минус билгесе белән була. Шул ук вакытта ел фасыллары алышынган вакытта температураның үзгәреше аеруча сизелерлек була, яз көне температураның күтәрелеше көз көне аның түбәнәюенә караганда тизрәк бара. Температура үсешенең аеруча тизләнүе кышкы айлар өчен хас.

Климат режимына барико-циркуляция процесслары сизелерлек йогынты ясый. Республика территориясе буенча атмосфера басымының күпеллык уртача күрсәткечләре (1966–2004 еллардагы күзәтүләр) аерым айларда, аеруча җәй көне, чагыштырмача аз үзгәрә (0,5–2,9 гПага). Ел әйләнешендә атмосфера басымының иң зур күрсәткечләре – салкын вакытта, иң түбәннәре җылы вакытта билгеләнә. Уртача айлык басым мартта 1020,7–1022,5 гПа күрсәткеченнән алып июльдә 1010,5–1011,3 гПа күрсәткеченә кадәр үзгәрә; ел әйләнәсендә аның тирбәлеше 9,5–11,7 гПа тәшкил итә, ә еллык уртача басым 1015,1–1016,9 гПа күрсәткеченә тигез. Тикшеренү уздырыла торган чорда атмосфера басымының еллар арасында үзгәрешләре, аның берничә елга бер кабатлануы белән, түбән ешлыктагы тирбәнешләре фонында уза. Шулай ук кышкы айларда (гыйнвар, февраль) басымның әкренләп түбәнәюе күзәтелә. Ул аеруча соңгы елларда циклон процессларының артып китүе шартларында һава температурасы күтәрелүнең тиешле трендлары белән раслана.

Температура һәм атмосфера басымы режимнары белән беррәттән, төбәктәге һава торышы мөһим сыйфатламаларының берсе булып аның дымлылыгы тора. Татарстан Республикасы территориясе буенча чагыштырмача дымлылык таралуның географик үзенчәлекләре ике фактор йогынтысы белән билгеләнә: су пары басымы һәм һава температурасы. Төбәк чикләрендә һава температурасының чагыштырмача тирбәлешләре пар басымы үзгәрешләреннән бераз кимрәк, бу исә җылы ел фасылы өчен бигрәк тә акланган. Нәтиҗә буларак, әлеге ел фасылында республика территориясе буенча һаваның чагыштырмача дымлылыгы һәм пар басымының таралуында шактый охшашлык күзәтелә. Җәй көне чагыштырмача дымлылыкның иң зур күрсәткечләре Идел һәм Кама үзәннәренә һәм Кама аръягының аларга килеп тоташкан Көнбатыш һәм Көнчыгыш (төньяк-көнбатыш өлеше) территорияләрендә күзәтелә. Елның салкын вакытында Татарстан Республикасының аерым территорияләре арасында температура контрастлыгы арта, ул чагыштырмача дымлылыкның географик бүленеше шартларының территория буенча пар басымына бәйлелеге берникадәр йомшаруын китереп чыгара.

Татарстан Республикасы территориясенең климат шартларын тулырак сыйфатлау өчен, коры һәм дымлы көннәр турында мәгълүмат китерергә

кирәк. Күзәтү вакытының сигездән берендә генә булса да чагыштырмача дымлылык 30 проценттан артмаса, андый көн коры дип санала. 12–15 сәгать буена чагыштырмача дымлылык 80 проценттан ким булмаган көн дымлы дип санала. Иң күп коры көннәр – майда, ә иң күп дымлы көннәр ноябрьдә (яки декабрьдә) була. Майда коры көннәр саны тиз арта – көньяк юнәлештә 6-7 дән (Тәтеш шәһәре, Чистай шәһәре), көнчыгышта (Минзәлә шәһәре – 12) һәм көньяк- көнчыгыш юнәлештә (Бөгелмә шәһәре – 14 көн). Ноябрь аенда дымлы көннәр саны 21 дән (Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы, Алабуга шәһәре, Мөслим авылы, Азнакай шәһәре) алып 24 көндә (Тәтеш шәһәре, Лаеш шәһәре) кадәр була. Иң күп коры көннәр территориянең калку урыннарында (периферия), ә иң күп дымлы көннәр аның түбәндә урнашкан өлешләрендә (Идел һәм Кама үзәннәре) күзәтелә.

Төбәк буенча уртача явым-төшемнең күпьеллык суммасы 503 мм тәшкил итә. Җылы вакытта (апрель – октябрь) 350 мм явым-төшем ява, бу салкын вакытка караганда ике тапкырга артыграк (ноябрь – март) – 151 мм. Явым-төшемнәрнең уртача айлык суммалары буенча шулай ук еллык әйләнеш яхшы күренә. Атмосфера явым-төшемнәре төрле масштабтагы һава циркуляциясе процессларының үзара йогынтысы нәтиҗәсе булып тора. Моннан тыш, территория буенча явым-төшемнәрнең таралышына биеклек, урын рельефының формасы һәм ориентациясе, зур урманнар, елгалар, елга үзәннәре булуы яки булмавы һ.б. тәэсир итә. Шуңа күрә атмосфера явым-төшемнәре таралышында шактый төрлелек күзәтелә.

Билгеле бер чорда җылылыкның микъдарын сыйфатлаганда актив һәм нәтиҗәле температураларның суммасы күрсәткечләре карап тикшерелә. Алар уртача климатта үсемлекләрнең актив үсеш чорында җылылык белән тәэмин ителешне күрсәтәләр. Актив температураларның суммасын 10°С тигез һәм аннан югарырак булган уртача тәүлек температуралары тәшкил итә. Нәтиҗәле температуралар суммасы билгеле төр үсемлекләр үсә торган биологик минимумнан саналган уртача тәүлек температураларын кушкач килеп чыга. Төрле үсемлекләрнең үсеше өчен кирәкле биологик температура минимумы төрлечә була. Нәтиҗәле һәм актив температуралар экологик әһәмияткә ия, үсемлекләрнең яшәү тирәлеге белән бәйләнешен чагылдыралар (атмосфера – гидросфера – литосфера). 5°С югары нәтиҗәле температуралар суммасы республика территориясендә – 1600–1700 °С, ә 10°С югарырагы 800–900 °С тәшкил итә, иң түбән күрсәткечләр Бөгелмәдә була (780°С). Актив температуралар суммасы төбәк буенча 2190 °С алып (Бөгелмә) 2300°С кадәр (Чулпан авылы, Алабуга шәһәре, Лаеш шәһәре, Мөслим авылы, Казан шәһәре) буенча үзгәрә.

Территориянең дымлылык шартларын сыйфатлаганда гидротермик коэффициент куллана (ГТК). ГТК = 1 күрсәткече дымлылыкның тулысынча сарыф ителүен аңлата; 0,5 ≤ ГТК ≤ 1 – корылык, җитәрлек дым юк; ГТК < 0,5 – бик коры; ГТК > 1 – дымлылык артык. Җәй көне ГТК республика территориясе буенча майда 0,5–0,6 дан июнь-август 0,8–1 кадәр үзгәрә, Чистай гына чыгарылма булып тора, анда ГТК 0,7 гә тигез.

Атмосферада корылык чагылышының үзенчәлекләре корылык индексы Si буенча билгеләнә, ул һава һәм явым-төшемнәр температурасының айлык күрсәткечләре буенча исәпләп чыгарыла. Корылыкның яисә дымлылыкның дәрәҗәсен әлеге критерийлардан чыгып Si билгелиләр: Si = 1–2 – көчле булмаган корылык; Si = 2–3 – уртача корылык; Si ≥ 3 – көчле корылык; Si = –1…+1 – нормаль дымлылык шартлары; Si = –1…–2 – җитәрлек дәрәҗәдән артыграк дымлылык; Si = –2…–3 – җитәрлек дәрәҗәдән уртача артык булган дымлылык; Si = ≤ -3 – җитәрлектән дәрәҗәдән нык артык дымлылык. Татарстан Республикасы территориясендә Si индексы буенча дымлылыкның нормаль шартларының кабатлануы: майда – 30,8 % (Тәтеш шәһәре) - 57,6 % (Алабуга); июньдә – 36,8 % (Чулпан авылы) - 57,7 % (Чистай шәһәре); июльдә – 33,3 % (Мөслим авылы) - 59,3 % (Чистай шәһәре); августта – 46,2 % (Минзәлә шәһәре, Арча шәһәре) - 74,1 % (Чистай шәһәре). Корылык һәм артык дымлылык чорларының кабатлану чагыштырмасы бертигез һәм җылы чорның һәр аенда (май – август) 5÷15 % тәшкил итә.

Климат факторлары арасында Татарстан Республикасы аучылык ресурсларының таралуына һәм санына иң зур йогынты ясаучысы – начар һава шартлары.

Мәсәлән, озак вакыт коры һава торган очракта, хайван азыгы булган үсемлекләр корый, шуңа күрә ау хайваннарының азыгы кими.

Җирдәге туң тирәнлеге кар катламының калынлыгына бәйле, ә ул исә хайваннарның кышын азык табу сәләтенә шактый йогынты ясый. Әйтик, кабан дуңгызы азыкны җирнең югары катламыннан казып таба. Карның өске йомшак катлавында көртлекләр семьялыгыннан булган кошлар ерткыч җанварлардан саклану өчен өн ясыйлар. Моннан тыш, кардагы өннәрдә организмның җылылык сарыф итүе кими. Кар катламы юка булган салкын кышларда сай сулыклар ката һәм аларда яшәүче хайваннар үлеп бетәргә мөмкин.

Кыш көне һаваның кыска вакытка җылынуы нәтиҗәсендә каты кар катламы барлыкка килә. Бу, үз чиратында, тояклы хайваннарның һәм урман кошларының тереклегенә начар тәэсир итә. Җылыткан вакытта яңгыр һәм юеш кардан урман кошларының төп кышкы азыгы (каен бөресе һәм нарат ылысы) боз белән каплана һәм кошлар аны ашый алмый. Җир өстендәге азыкны табу кыенлашудан тыш, боз катламы тояклы хайваннарның аягын да яралый.

Соңлаган язгы суытулар урман һәм су кошларының салган күкәйләре һәм иртә чыккан чебешләре туңуга китерә, шулай ук аучылык хайваннарының азык үләнен юк итә.

Җилнең көче шулай ук аучылык ресурсларына билгеле бер тәэсир ясый. Мәсәлән, кыйммәтле мехлы хайваннарның йон капламы җитешү тизлегенә октябрь аенда көчле җилләр күп исүнең йогынтысы яхшы була. Шуңа күрә тиен, сусар, ас, янутсыман эт һәм чәшкенең мехлары шактый иртә (ноябрьнең беренче декадасы беткәндә) кыйммәтле мех стандартлары таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә өлгерә.

## 2.3. Татарстан Республикасы территориясе рельефының сыйфатламасы

Татарстан Республикасында территория рельефы аучылык хайваннарына, нигездә, читләтеп тәэсир итә. Андый тәэсир ерганак-чокыр, түбәнлек-калкулыклардан торган катлаулы рельефлы зоналарда микроклимат характеристикалары үзгәрү аркасында килеп чыга. Рельефның тәэсире шулай ук урынның ышыклану өчен җай тудыруында чагыла. Әйтик, Татарстан Республикасында чокырлар челтәре кабан дуңгызлары, коралайлар һәм соры көртлекләргә уңай шартлар тудыра. Рельеф шулай ук чикләүче фактор булып та чыга, чөнки тояклы һәм ерткыч хайваннарның яшәү тирәлеге моның өчен яраксыз территорияләр – чокырлар, текә ярлар хисабына кими.

Татарстан Республикасы территориясе урман һәм урман-дала зонасында урнашкан, Иделнең уң ярында һәм республиканың көньяк-көнчыгышында зур булмаган калкулыклары булган тигезлекне тәшкил итә. Территориянең 90% диңгез өслегеннән 200 метр биеклектә урнашкан. Республика территориясен шартлы рәвештә 3 географик зонага бүләләр.

1. Кама алды зонасы – Казан һәм татар катламнары токымнары тәшкил иткән борынгы Пермь катламыннан торучы, өслеге төньяктан көньякка Камага таба, Идел үзәненә көнбатышка һәм Кама үзәненә көнчыгышка таба урыны-урыны белән авышлыклары булган калку тигезлек ул. Абсолют биеклек уртача 170–190 м тәшкил итә, ә төньякта 200 метрдан артып китә. Казанка, Мишә, Шушма, Нократ, Тойма, Иж елгаларының һәм аларның кушылдыклары үзәннәре субүләрләр массивлары белән бүленгән. Мондый массивлар урыны-урыны белән Казан катламы гипсы катнашкан исвестняктан, доломиттан, татар катламының кызыл балчыгыннан, мергельдән, ком ташыннан (плитә рәвешендә, артык каты булмаган) тора.

2. Идел алды зонасы нигездә тигез рельефлы. Татарстан Республикасының Чүпрәле районында рельефның 240 метрга җитә торган иң югары нокталары урнашкан. Идел алды Урман-дала зонасының төп өслеге көньяктан төньякка таба авыш. Зонаның төньяк-көнчыгыш өлешендә хәзерге вакытта сөзәклекле эрозия процесслары башланган, алар чокырларның тирәнәюен һәм текә тау битләрендә, гадәттә көньяк һәм көнчыгыш экспозицияләрдә, туфрак катлавының юылуын китереп чыгара. Елга үзәннәренең, чокырларның, сызаларның типик ассиметриясе аркасында елгалар арасындагы субүләрләрнең асимметриясен китереп чыгара. Идел һәм Зөя арасындагы таулар тезмәсе бигрәк тә эрозияләнеп ермачланган. Көньяк-көнбатыш районнар (Чүпрәле, Буа, Тәтеш) мезозой эрасының соңгырак чор геологик токымнарыннан (акбур һәм юра катламы токымы) оешкан рельефлы булуы белән аерылып тора. Башлыча карасу төстәге коры дип әйтерлек балчыкның өстенлек итүе су челтәренең сирәклегенә, чокырларны сызалар алыштыруга китерә. Көньякта Зөя үзәнендә эрозиянең төньякта урнашкан Идел базисыннан ераклыгы һәм эрозия челтәренең күтәренкелеге сәбәпле эрозиянең тирәнәюе җитлеккән үзәнле-сызалы җирлек системасының формалашуына ярдәм итә.

3. Идел аръягы зонасы рельеф һәм геологик төзелеше ягыннан өч геоморфологик районга бүленә. Көнбатыш-Кама аръягы – Пермь һәм плиоцен катламнарыннан торган һәм башлыча голоцен чорының балчыксыл делювиаль һәм элювиаль туфрагы белән капланган, абсолют биеклеге 120 – 140 м булган тигезлек-үзән. Бөгелмә-Шөгер ике катламлы яссы тау (380 м җитә), эрозия белән ермачланган, геологик төзелешендә карбонатлы-комлы катлам өстенлек иткән Пермь системасының Уфа, Казан һәм татар катламнарыннан оешкан. Субүлемнәр өслегендә – балчыксыл делювиаль туфрак һәм карбонатлы (башлыча) аллювиаль туфрак. Кама аръягы-Бельск тигезлек-үзәне – башлыча плиоцен катламыннан оешкан һәм делювиаль балчыксыл туфрак белән капланган (абсолют биеклеге 130 – 160 м тәшкил итә).

## 2.4. Өстенлек иткән туфрак төрләре һәм аларның бүленеше

Татарстан Республикасы территориясенең урман һәм урман-дала зоналары чигендә урнашуы туфракның төрле составлы һәм ясалыш шартлары катлаулы булуын билгели. Республиканың төньягыннан көньягына хәрәкәт иткән саен урман үсемлекләренә хас булган туфрак ясалу процесслары әкренләп көчсезләнә һәм, киресенчә, үләнле үсемлекләргә хас туфрак ясалу процесслары көчәя. Шул ук вакытта конкрет территориянең асыл катламнары, рельефы, микро- һәм мезоклимат үзенчәлекләре бик зур роль уйный. Шуңа күрә республиканың һәр физик-географик өлешендә туфрак катлавы теге яки бу туфрак төренең, аларның гаять төрлелеге фонында, өстенлеге белән сыйфатлана. Республиканың төньягында һәм көнбатышында соры урман һәм көлсу туфрак өстенлек итә, көньякта 32% территорияне кара туфрак алып тора. Соры урман һәм тозы юылган кара туфрак өстенлек алганда, аеруча уңдырышлы кара туфрак очрый. Туфрак төренә карап Татарстан территориясе шулай ук өч районга бүленә:

1. Урманлы Идел аръягы зонасы.

Монда туфрак төрләренең бүленеше төрлечә. Соры урман туфрагы Урманлы Идел аръягының туфрак фонды мәйданының 64 процентын, ә чирәмле-көлсу туфрак – 20,7 процентын, тугайлык туфрагы – 10,4 процентын, саз һәм ярымсаз туфрагы – 1,8 процентын алып тора һәм чокырлар, текә тау битләре өлешенә мәйданның 2,7 проценты туры килә. Соры урман туфрагы төньяк урман-дала ландшафтын билгели. Беренчел табигый хәлендә ландшафт киң яфраклы урманнардан гына тормаган, бәлки болын үсемлекләре үскән шактый зур кишәрлекләр дә булган, шулай ук көньякка һәм көнбатышка караган, җылылык һәм яктылык мул төшкән тау битләре, төньяк урман-дала вариантындагы шикелле, урман-болын үсемлекләре белән капланган булырга мөмкин дип фаразлана. Имән, юкә, өрәңге кебек киң яфраклы агач төрләре үсү өчен карбонатлы токымнарның җир өстендә үк яки аңа якын ятуы бик мөһим була.

2. Урман-далалы Идел алды зонасы.

Урман-далалы Идел алдында территориянең дымлылыгына, эрозиялардән ермачлануына, өске катлаудагы тау токымнарының гидрогеологик үзенчәлекләренә карап, туфрак районнары икәү дип бүлеп чыгарыла. Көньяк-көнбатышта кара җир тибындагы туфрак 81% тәшкил итә, күпчелектә алар тозсызланган кара җир (76%), соры урман туфрагы 6 процентны тәшкил итә, 10 % тирәсе мәйданны тугай туфрагы, саз һәм ярымсаз туфраклары биләп тора, ә шулай ук хуҗалык итү өчен яраксыз җирләр – текә һәм кысыр тау битләре һәм чокырлар. Мәйданның якынча 2 процентын чирәм-көлсу туфрак тәшкил итә. Төньяк-көнчыгыш өлештә туфрак төркемнәренең бүленеше төрлечә. Пермь чорына караган, гаять ермачланган рельеф тәшкил итүче токымнарның үсеше чикләрендә кара җир тибындагы туфрак мәйданның 29 процентын алып тора. Урман туфрагы, күбесенчә соры һәм кара-соры, шулай ук ачык-соры, коңгырт-соры, коңгырт чирәмле-көлсыман туфрак мәйданның 57 процентын тәшкил итә. 10 процент тирәсе мәйдан тугай туфрагына туры килә, ә сазлык һәм ярымсазлык туфрагы мәйданның 1,2 процентын алып тора.

3. Урман-далалы Идел аръягы зонасы.

Урман-далалы Идел аръягы зонасы көнбатыш өлешенең туфрак катламы күбрәк кара балчыклы, шул ук вакытта тозсызланган кара туфрак мәйданның 52,2 процентын, гадәти кара туфрак 13,3 процентын һәм урман кызыл балчыгында карбонатлы кара туфрак 1,8 процентын алып тора. Урман туфрагы мәйданның 32,6 процентын алып тора, 28,3 проценты киң яфраклы урманнар үсә торган мәйданнарга хас соры һәм кара-соры туфракка туры килә. Көньяк-тайга тибы туфрагы – чирәмле-көлсыман туфрак – нибарысы 1,2 % тәшкил итә. Зур булмаган мәйданда – ачык-соры, коңгырт һәм коңгырт-соры туфрак. Мәйданның 10 процентын тугай һәм сазлык туфрагы тәшкил итә. Кама-Бельск тигезлегендә урман тибындагы туфрак 41 процентны, тугай, сазлык һәм ярымсазлык туфрагы 14 проценттан артыграк мәйданны тәшкил итә. 1 проценттан артык мәйданда көньяк һәм көнбатыш экспозицияләрнең үсемлексез текә ярлары тора. Урман тибындагы туфракта соры, кара-соры һәм ачык-соры туфрак өстенлек итә – 33%. Коңгырт һәм коңгырт-соры туфрак мәйданның 8 процентын диярлек били. Чирәмле-көлсыман туфрак мәйданы 2 процентны тәшкил итә. Кара туфракның 40 процентын тозсызланган кара туфрак, гадәти кара туфрак – 6,5 процентын, 3 процент тирәсен – карбонатлы кара туфрак тәшкил итә. Кара туфрак рәте: уртача калынлыктагы, калын катламлы һәм тозсызланган, гадәти, уңдырышлы кара җир черемәнең күп булуы, азотның һәм фосфорның тулай микъдары һәм алмашу процессларының тиз баруы, шулай ук су суспензиясенең нейтраль яки көчсез селтеле реакциясе белән сыйфатлана.

Татарстан Республикасының көньяк өлешендә (аерым алганда, Әлмәт, Азнакай, Бөгелмә, Баулы һәм башка районнар) сөрелә торган катламда черемә аеруча күп микъдарда (8 проценттан артык).

## 2.5. Татарстан Республикасы территориясендә гидрография челтәре

Төбәкнең гидрография челтәре тармакланган елгалар челтәре, шул исәптән зур елгалар һәм аларның кушылдыклары белән, уртача зурлыктагы һәм кечкенә елгалар белән сыйфатлана. Татарстан Республикасы территориясе буйлап Идел (177 км), Кама (380 км), Нократ (60 км), Ак (50 км) елгалары, шулай ук кечерәк елгалар ага. Су агымнарының гомуми саны 9965 кә җитә. Елгалар типик тигезлек режимында, аларда язгы ташкын, җәйге һәм кышкы саегу һәм артык көчле булмаган көзге ташкын була. Су күләме уртача булган елларда 1 кв.км территориягә агым күләме 8,59 куб.км яки елына 126,3 куб.м була. Су агымының 75 проценты язгы ташу вакытына туры килә. Елга челтәренең тармаклану коэффициенты Татарстан Республикасы территориясе буенча су агышы бүленешенең күрсәткече була. Ул 0,11дән 0,80 км/кв.км.га үзгәрә, 0,25–0,45 км/кв.км кадәр өстенлек итә. Республиканың су агымнарының гомуми санынннан озынлыгы 10 километрдан артмый торган 3686 елга кечкенә елга булып санала.

Татарстан Республикасының тикшерелә торган предметның гидрография челтәрен сыйфатлау өчен әһәмияте булган кечкенә елгалары:

1. Әрә. Гомуми озынлыгы 56,4 км. Татарстан Республикасы территориясендә Зөя елгасына кушыла.

2. Зур Чирмешән – Идел елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы – 336 км, бассейны мәйданы – 11 500 км, тамагында суның уртача чыгымы 36,1 куб. м/с.

3. Бола – Зөя елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы 127,7 км.

4. Болак – Казан шәһәрендә Түбән Кабан күлен Казансу елгасы белән тоташтыра торган ермак.

5. Казансу – Идел елгасының сул кушылдыгы. Озынлыгы якынча 140 км, бассейны мәйданы 2600 км. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә Идел елгасына коя.

6. Мишә – Кама елгасының уң кушылдыгы, Куйбышев сусаклагычының Кама култыгына кушыла. Озынлыгы 204 км, бассейны мәйданы 4180 кв.км.

7. Зөя – Идел елгасының уң кушылдыгы. Озынлыгы 375 км, бассейны мәйданы 16700 км.

8. Кара Бизнә – Бизнә елгасының сул кушылдыгы. Татарстан Республикасының Чүпрәле районы территориясе буйлап ага. Озынлыгы – 34,0 км, бассейны мәйданы - 242,1 км.

Төбәкнең күпчелек күлләре морфометрик сыйфатлары буенча кечкенә күлләр категориясенә керә. Чагыштырмача зур 30 га якын күл бар (мәйданы 20 – 100 га, шуннан артыграк мәйданлылары да бар). Аеруча зур күлләр: Казан шәһәрендә Урта (112 га), Түбән (56,0 га) һәм Югары Кабан (25,0 га), Казан шәһәре чикләрендә Аккош күле системасы, Лаеш районында Кавал (88,2 га) һәм Тарлаш (60,1), Зеленодольск районында Раифа (32,3 га) һәм Ильинский (27,5 га), «Түбән Кама» милли паркында Подборное (33,0 га) күлләре. Күпчелек күлләр сай сулыкларга карый (1 - 3 м). Карстлы күлләр

арасында, шул исәптән бик кечкенәләре арасында, тирәннәре дә очрый – 20 метрга кадәр һәм тирәнрәк.

Төбәкнең гидрология режимында сусаклагычларның әһәмияте шактый зур:

1. Карабаш сусаклагычы. Карабаш п. янында урнашкан. Карабаш поселогыннан алып Бигеш авылына кадәр аралыкта нефть чыгару һәм сәнәгать предприятиеләре өчен су чыганагы булып тора. Сусаклагычтагы суның тулы күләме – 52,4 млн.куб.м.

2. Түбән Кама сусаклагычы. Вакытлыча билгесе 62,0 м булганда тулы күләме 2,9 куб.км, су өслегенең мәйданы 1,084 мең кв.км. тәшкил итә.

3. Зәй шәһәре янындагы Зәй сусаклагычы. Сусаклагычтагы суның тулы күләме – 0,063 куб.км, су өслегенең мәйданы – 20,45 кв.км.

4. Куйбышев сусаклагычы. Тулы күләме 57,3 куб.км. тәшкил итә. Акваториясе берничә чиктәш төбәк территориясендә, су өслеге мәйданының 50,7 проценты (якынча 3,12 мең кв.км)Татарстан Республикасында урнашкан. Яр сызыгының гомуми озынлыгы – 2604 км, шуның 1392 километры (53,5 %) Татарстан Республикасында урнашкан.

Шунысын әйтеп китәргә кирәк, Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычлары кебек зур сулыкларны хайваннарның яшәү тирәлеге буларак шартлы рәвештә генә карап булмый. Гаять киң булулары сәбәпле, аларда кош-корт, җәнлек-җанварларның күпчелек төрләре оя кора алмый. Текә ярлар, суның еш күтәрелүе һәм төшүе белән бергә, су янында көн итүче төрләрнең үрчүенә киртә була.

## 2.6. Үсемлек капламының сыйфатламасы

Республикада үсемлек капламы нигездә флорогенетика комплексларының бореаль, немораль һәм понтика төрләреннән тора. Флорада шулай ук көнчыгыш (Урал һәм Себер) һәм көньяк-көнчыгыш (Көнчыгыш Европа-Казахстан) элементлары катнашуы сизелә.

Төбәкнең ылыслы мәңге яшел урманнары гадәти чыршыдан (Picea abies), Ак Себер чыршысыннан (Abies sibirica) һәм гадәти нараттан (pínus sylvéstris) тора. Вак яфраклы агач төрләре өстенлек алган катнаш урманнар хәзерге вакытта аеруча таралган. Мондый урманнарда усак (Populus tremula),каен (Betula pendula), вак яфраклы юкә (Tília cordáta) аеруча еш очрый. Тиешенчә Киң яфраклы агач төрләре дә булган катнаш урманнар (киң яфраклы төрләр 30 проценттан кимрәк) һәм киң яфраклы урманнар (киң яфраклы төрләр 30 проценттан артык) азрак мәйданны били. Киң яфраклы төрләр арасында иң күп таралган агач – имән (Quércus róbur). Вак яфраклы агач төрләреннән торган урманнар зур булмаган мәйданда урнаша. Гадәттә зур булмаган күпчелек урман массивларында яшь агачлар өстенлек итә.

Тайга зонасының көньяк чиге булып торган ылыслы урман массивлары территориаль яктан Идел аръягында урнашкан. Аларны составына еш кына төрле санда вак яфраклы һәм киң яфраклы агач төрләре кергән чыршы-ак чыршы һәм нарат урманнары тәшкил итә. Төбәк территориясенең

көньягындарак яфраклы урманнар бар, аларда имән урманнары мөһим урын алып тора. Алар Татарстан Республикасының бөтен районнарында да очрыйлар, көнчыгыш юнәлештә кими баралар. Идел алдында күбесенчә яфраклы, имән үсә торган аз санлы урманнар бар. Төньяк-көнбатыш өлештә катнаш урманнар массивлары урнашкан. Идел-Нократ-Кама субүләрләрендә күпсанлы яфраклы агачлар катнашкан чыршы-ак чыршы төре таралган. Татарстан Республикасының көньяк өлеше урман-дала зонасына керә. Хәзерге вакытта төбәктә дала зонасына карый торган җир кишәрлекләре Кама аръягының көньяк-көнчыгыш субүләрләрендә, шулай ук субүләрләрнең күпчелектә көньякка, көньяк-көнчыгышка, көньяк-көнбатышка караган текә сөзәклекләрендә генә очрый. Бу кишәрлекләр Пермь чорының аларның җир өслегенә якын урнашуы җир сөрүне кыенлаштыра торган (туфрак катлавының калынлыгы 15-20 сантиметрдан артмый) төп токымнарыннан (мергель, мергельле таш һәм балчык) оешкан.

Татарстанның хәзерге заман үсемлекләр капламында шактый зур урынны агрофитоценозлар алып тора. Аларның 91 проценты сөрүлек җирләренә туры килә. Калган мәйданны печәнлекләр һәм көтүлекләр алып тора. Чәчүлек мәйданнарының нигезен бөртекле культуралар тәшкил итә, шулардан бодай (Triticum), арыш (Secále cereále) һәм арпа (Hordeum vulgare) аеруча зур әһәмияткә ия. Азрак дәрәҗәдә кырларга солы (Avéna satíva), карабодай (Fagópyrum) һәм борчак (Pisum sativum) чәчелә. Техник культуралар арасында силос ясау өчен тотыла торган кукуруз (Zéa máys), бәрәңге (Solánum tuberósum) һәм шикәр чөгендере (Beta vulgaris) аеруча зур әһәмияткә ия. Эшкәртелмәгән территорияләрдә чүп үләне төрләре киң таралган.

Татарстан Республикасында коры үзән һәм кыяклы дала үләннәре үсә торган болыннар киң таралган. Зур булмаган тугайлар кечкенә елгалар өчен хас. Болыннар төпләнгән урманнар урынында хасил булган, аларда печән чабалар һәм терлек көтәләр. Татарстанның көньяк районнарында урыны-урыны белән дала куаклыкларыннан торган әрәмәләр очрый, аларның төп төрләре – куаклы чия (Cerasus fruticosa), дала бадәм агачы (Amygdalus nana), спирея (Spiraea crenata), алар шулай ук төпләнгән урман урынында үскән. Көньяк экспозицияләрнең текә сөзәклекләрендә оя-оя дала үләннәре сакланган, шулардан ташлы дала дип аталганнары составына бик борынгы төрләр керә: ике башаклы ылыслы куак (Ephedra distachya), җәелгән кохия (Kochia prostrata), куаклы курчавка (Atraphaxis frutescens). Тозлы туфраклы яшәү тирәлекләрендә галофит үләннәр зур булмаган мәйданда үсә: диңгез сөтлегәне (Glaux maritima), тозлак солерос (Salicornia perennans) һ.б.

Су һәм су яны үсемлекләренең тереклеге сулыкларга һәм су агышына бәйләнгән. Боларның иң күп таралышы Куйбышев һәм Түбән Кама сусаклагычларына туры килә. Анда су яны үсемлекләреннән озынча яфраклы камыш (Typha angustifolia) һәм гадәти камыш (Phragmites australis) оя-оя булып үсә. Сусаклагычларның һәм күлләрнең су яны үсемлекләре составында зур комай (Glyceria maxima), саз үләне (Eleocharis palustris) һәм кыякларның күп кенә төрләре (Carex) шулай ук шактый зур рольне уйный,

суүсемнәр составында – куе яшел мөгезъяфрак (Ceratophyllum demersum), Канада элодеясы (Elodea canadensis), сары төнбоек (Nuphar lutea) һәм су кәбестәсе төрләре (Potamogeton).

## 2.7. Хайваннар дөньясы

Төбәктәге хайваннар дөньясының байлыгы һәм күптөрлелеге республиканың ике ландшафт зонасы (урман һәм дала) чигендә урнашуына бәйләнгән. Хәзерге вакытта республикада имезүчеләрнең 71 төре, кошларның 290 төре, сөйрәлүчеләрнең 7 төре (Татарстан Республикасы фаунасыннан сазлык ташбакасы юкка чыккан), җир-су хайваннарының 11 төре, балыкларның 43 төре һәм умырткасыз хайваннарның меңәрләгән төре, шуларның биш меңнән артыгы – буынтыкаяклылар, санала («Татарстан Республикасының табигать ресурслары торышы һәм 2019 елда әйләнә-тирә мохитне саклау турында» дәүләт доклады).

Умырткасызлар.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы территориясендәге умырткасызларның билгеле бер системага салынган төркемнәрендәге төр күптөрлелеге буенча өзек-төзек мәгълүматлар гына бар. Элпә канатлыларның 304 төре, бызылдавыкларның 303 төре, стафилиннарның 250 дән артык төре, шыртлавык коңгызларның 35 тән алып 50 гә кадәр төре билгеле. Умырткасызларның 107 төре Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән.

Сөякле балыклар.

Күп санлы тикшеренүләр йомгаклары буенча 2012 елда Татарстан Республикасы территориясендәге ихтиология фаунасының 58 төре күрсәтелә, табылган барлык төрләр җилпәзәканатлыларга (Actinopterygii), 11 отряд, 17 семьялык һәм 48 төренә керә. Татарстан Республикасының Кызыл китабына (3 нче басма) балыкларның 11 төре кертелгән. Мәрсин балыгы семьялыгыннан (Acipenseridae) 3 төр - рус мәрсин балыгы (Acipenser gueldenstaedtii), чөгә балыгы (Acipenser ruthenus) һәм кырпы балыгы (Huso huso); карплар семьялыгыннан (Cyprinidae) 4 төр - гадәти маймыч (Rhodeus amarus), гади елгыр балык (Alburnoides bipunctatus),Идел каракойрыгы (Chondrostoma variabile), күлләргесе (Phoxinus percnurus); бәрделәр семьялыгыннан (Thymallidae) 1 төр – Европа бәрдесе (Thymallus thymallus); сөләйман балыгы семьялыгыннан (Salmonidae) 2 төр – таймень (Hucho taimen) һәм инеш керкәсе (Salmo trutta morpha fario); Керчәклеләр мөгезле балыклар семьялыгыннан (Cottidae) 1 төр – гадәти таш асты балыгы (Cottus gobio).

Татарстан Республикасының хәзерге ихтиофаунасы 9 фауна комплексыннан тора. Бүтән сулыклардагы кебек, Урта Идел бассейнының ихтиофаунасы нигезен ике фауна комплексы тәшкил итә: 13 борealь тигезлек төре (чуртан, бәртәс, чабак, карабалык, гадәти кәрәкә, көмеш кәрәкә, гадәти щиповка, Себер щиповкасы, күл ләргесе, йомры чабак, гадәти ташбаш, алабуга, шыртлака) һәм унөч понто-каспий төче сулык төре (кызылканат,

верховка, җилембалык, корбан балыгы, тәлпияк, ак каурыйлы ташбаш, синец, аккүз, быстрянка, опты, түбәнавыз, кушбаш, чехонь). Балыкларның 9 төре амфибореальгә керә (судак, сазан, этләч, сула, җәен, маймыч, кырпы балыгы, чөгә, мәрсин), понто-каспий диңгез – 6 төр (пуголовка, кушбаш, йомры кискә, цуцик, энә, тюлька), тау яны бореаль – 5 төр (елга ләргесе, мыеклы сагалак, бәрде, таймень, таш асты балыгы), Кытай-тигезлек – 3 төр (ак ташмаңгай, чуар ташмаңгай, амур). Татарстан Республикасы ихтиофаунасында һинд-тигезлек (ротан) һәм атлантик диңгез комплексыннан (еланбалык) берешәр төр бар.

Җир-су хайваннары һәм сөйрәлүчеләр.

Татарстан Республикасының җир-су хайваннары һәм сөйрәлүчеләр фаунасында 2 төркем җир-су хайваны һәм 2 төркем сөйрәлүче бар: ташбакалар (Testudines), тәңкәлеләр (Squamata), койрыклылар (Caudata) һәм койрыксызлар (Anura). Беренче сыйныфка 5 семьялык керә: төче су ташбакалары (Emididae) (1 төр), бакыр еланнар (Anguidae) (1 төр), чын кәлтәләр (Lacertidae Cope) (2 төр), тузбашлар(Colubridae) (2 төр), кара еланнар (Viperidae) (2 төр). Икенчесенә саламандрлар семьялыгы (Salamandridae) (2 төр), түгәрәктеллеләр (Discoglossidae) (1 төр), сарымсак килеселәре (Pelobatidae) (1 төр), гөберле бакалар (Bufonidae) (2 төр) һәм бакалар (Ranidae) (5 төр) керә. Сөйрәлүчеләрдән 4 төр (барлык сөйрәлүчеләр төреннән 62,5%) һәм җир-су хайваннарыннан 3 төр (барлык җир-су хайваннарыннан 27,2%) Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән.

Кошлар.

Татарстан Республикасының орнитофаунасында чыпчыксыманнар төркеме (Passeriformes) аеруча нык таралган – 154 төр. Бу отрядта сан ягыннан чебенчеләр, миләш чыпчыклары һәм тау чыпчыклары өстенлек итә. Чыпчыксыман (Charadriiformes), казсыман (Anseres) һәм лачынсыман (Falconiformes) кош төркемнәре шулай ук төр ягыннан шактый бай.

Кошларның күпчелеге – күчмә кошлар. Кошларның якынча 40 төре ау кошлары булып санала. Елга үрдәкләре күп, чүрәкәйләр сан ягыннан шактый кайтыш.

Имезүчеләр.

Имезүчеләр исемлегенә 71 төр хайван кертелгән, әле тагын чүл бүресенең, Европа чәшкесенең, ярканатларның берничә төренең статусын ачыкларга кирәк Рус җофарын югалган төр дип танырга кирәктер, мөгаен. Ландшафтның төрлелеге (урман, дала, урман-дала, су яны һәм су комплекслары, бик борынгы һәм аз үзгәргән территорияләр) һәм аерым биотопларның чуарлыгы аркасында, Татарстан Республикасы территориясендә имезүчеләр составы катнаш характерда.

Аучылык ресурслары.

Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларына хайваннарның 78 төре керә, шуларның 30 төре – имезүчеләр һәм 48 төре – кошлар. Татарстан Республикасының аучылык ресурслары

структурасында аучылык хуҗалыгында киң кулланыла торган төрләр өстенлек итә. Республикадагы аучылык ресурсларының төрләргә бүленеше 1 нче таблицада күрсәтелгән.

1 нче таблица

Татарстан Республикасындагы аучылык ресурсларының төрләргә бүленеше

| Т/с | Аучылык ресурслары төрләренең татарча атамасы | Аучылык ресурслары төрләренең латинча атамасы |
|---|---|---|
| Төрләр | | |
| ИМЕЗҮЧЕЛӘР КЛАССЫ (Mammalia) | | |
| КУШТОЯКЛЫЛАР отряды (Artiodactyla) | | |
| Боланнар семьялыгы (Cervidae) | | |
| 1 | Поши | Alces alces |
| 2 | Себер кыр кәҗәсе | Capreólus pygárgus |
| 3 | Европа кыр кәҗәсе | Capreolus capreolus |
| Дуңгызлар семьялыгы Suidae | | |
| 4 | Кабан дуңгызы | Sus scrofa |
| ЕРТКЫЧЛАР отряды (Carnivora) | | |
| Бүреләр семьялыгы (Canidae) | | |
| 5 | Бүре | Canis lupus |
| 6 | Гади төлке | Vulpes vulpes |
| 7 | Янутсыман эт | Nyctereutes procyonoides |
| 8 | Дала төлкесе | Vulpes corsac |
| Мәчеләр семьялыгы (Felidae) | | |
| 9 | Селәүсен | Felis lynx |
| Сусарлар семьялыгы (Mustelidae) | | |
| 10 | Бурсык | Meles meles |
| 11 | Урман сусары | Martes martes |
| 12 | Дала көзәне | Mustela eversmanni |
| 13 | Урман көзәне | Mustela putorius |

| Т/с | Аучылык ресурслары төрләренең татарча атамасы | Аучылык ресурслары төрләренең латинча атамасы |
|---|---|---|
| 14 | Себер бурсыгы | Gulo gulo |
| 15 | Ләтчә | Mustela nivalis |
| 16 | Америка чәшкесе | Mustela vison |
| 17 | Себер көзәне | Mustela sibirica |
| 18 | Кама | Lutra lutra |
| 19 | Ас | Mustela erminea |
| Аюлылар гаиләсе (Ursidae) | | |
| 20 | Көрән аю | Ursus arctos |
| КИМЕРҮЧЕЛӘР отряды (Rodentia) | | |
| Кондызлар семьялыгы (Castoridae) | | |
| 21 | Елга кондызы | Castor fiber |
| Тиеннәр семьялыгы (Sciuridae) | | |
| 22 | Гади тиен | Sciurus vulgaris |
| 23 | Дала байбагы | Marmota bobak |
| 24 | Зур (җирән) йомран | Citellus major |
| Әрләннәр семьялыгы (Cricetidae) | | |
| 25 | Су күсесе | Ondatra zibethica |
| 26 | Гади әрлән | Cricetus cricetus |
| 27 | Су кыр тычканы | Arvicola terrestris |
| КУЯННАР отряды (Lagomorpha) | | |
| Куяннар семьялыгы (Leporidae) | | |
| 28 | Соры куян | Lepus europaeus |
| 29 | Ак куян | Lepus timidus |
| БӨҖӘКАШАУЧЫЛАР отряды (Insectivora) | | |
| Сукыр тычканнар семьялыгы (Talpidae) | | |
| 30 | Европа сукыр тычканы | Talpa europaea |

| Т/с | Аучылык ресурслары төрләренең татарча атамасы | Аучылык ресурслары төрләренең латинча атамасы |
|---|---|---|
| КОШЛАР КЛАССЫ (Aves) | | |
| ТАВЫКСЫМАННАР отряды (Galliformes) | | |
| Кыргавыллар семьялыгы (Phasianidae) | | |
| 31 | Соры кыр тавыгы | Perdix perdix |
| 32 | Бүдәнә | Coturnix coturnix |
| Көртлекләр семьялыгы (Tetraonidae) | | |
| 33 | Божыр | Tetrastes bonasia |
| 34 | Гадәти урман тавыгы | Tetrao urogallus |
| 35 | Көртлек | Lyrurus tetrix |
| 36 | Ак кыр тавыгы | Lagopus lagopus |
| ТОРНАСЫМАННАР отряды (Gruiformes) | | |
| Көтүче кошлар семьялыгы (Rallidae) | | |
| 37 | Су тавыгы | Fulica atra |
| 38 | Тартар | Crex crex |
| 39 | Гади кугыч | Porzana porzana |
| КАЗСЫМАННАР отряды (Anseriformes) | | |
| Үрдәк кошлар семьялыгы (Anatidae) | | |
| 40 | Ак маңгайлы каз | Anser albifrons |
| 41 | Ындыр казы | Anser fabalis |
| 42 | Соры каз | Anser anser |
| 43 | Чуар үрдәк | Tadorna tadorna |
| 44 | Кыр үрдәге | Anas platyrhynchos |
| 45 | Сыбызгы-чүрәкәй | Anas crecca |
| 46 | Черелдек-чүрәкәй | Anas querquedula |
| 47 | Соры үрдәк | Anas strepera |
| 48 | Безкойрык | Anas acuta |

| Т/с | Аучылык ресурслары төрләренең татарча атамасы | Аучылык ресурслары төрләренең латинча атамасы |
|---|---|---|
| 49 | Киң борынлы үрдәк | Anas clypeata |
| 50 | Сыбызгы-үрдәк | Anas penelope |
| 51 | Ала чумгалак | Bucephala clangula |
| 52 | Бүрекле кара үрдәк | Aythya fuligula |
| 53 | Кызыл үрдәк | Tadorna ferruginea |
| 54 | Кызыл башлы чумгалак | Aythya ferina |
| 55 | Четерек | Netta rufina |
| 56 | Диңгез кара үрдәге | Aythya marila |
| 57 | Ак күз кара үрдәге | Aythya nyroca |
| 58 | Ак яңаклы казарка | Branta leucopsis |
| 59 | Чумгалак үрдәк | Mergus merganser |
| 60 | Тундра-диңгез чумгалагы | Clangula hyemalis |
| 61 | Ак чумгалак | Mergellus albellus |
| ЧЫПЧЫКСЫМАННАР отряды (Charadriiformes) | | |
| Чуллыклар семьялыгы (Scolopacidae) | | |
| 62 | Чуллык | Gallinago gallinago |
| 63 | Урман үрдәге | Gallinago media |
| 64 | Теләттәвеч | Scolopax rusticola |
| 65 | Мородунка | Xenus cinereus |
| 66 | Кечкенә веретенник | Limosa lapponica |
| 67 | Уртача кроншнеп | Numenius phaeopus |
| 68 | Нәни Кроншнеп | Numenius minutus |
| 69 | Гаршнеп | Lymnocryptes minimus |
| 70 | Корыхтан | Philomachus pugnax |
| 71 | Гадәти  таш асты балыгы | Arenaria interpres |
| Арыш чыпчыклары гаиләсе  (Charadriidae) | | |

| Т/с | Аучылык ресурслары төрләренең татарча атамасы | Аучылык ресурслары төрләренең латинча атамасы |
|---|---|---|
| 72 | Бибек | Vanellus vanellus |
| 73 | Соры арыш чыпчыгы | Charadrius morinellus |
| 74 | Тулес | Pluvialis squatarola |
| КҮГӘРЧЕНСЫМАННАР отряды (Columbiformes) | | |
| Күгәрченнәр гаиләсе (Columbidae) | | |
| 75 | Күгелҗем күгәрчен | Columba livia |
| 76 | Әберчен | Columba palumbus |
| 77 | Божралы урман күгәрчене | Streptopelia decaocto |
| ЧЫПЧЫКСЫМАННАР Отряды (Passeriformes) | | |
| Каргалар гаиләсе (Corvidae) | | |
| 78 | Соры карга | Corvus cornix |

Саклана торган төрләр.

«Ау турында» гы законның 11 маддәсенең 4 пункты нигезендә, Россия Федерациясенең Кызыл китабына һәм Россия Федерациясе субъектларының Кызыл китапларына кертелгән имезүчеләрне һәм кошларны тоту тыела.

Татарстан Республикасы территориясендә имезүчеләрнең саклана торган төрләренә түбәндәгеләр кертелә:

Колаклы керпе (Erinaceus auritus, Gmelin, 1770), гади кутора (Neomys fodiens, Pennant, 1771), кечкенә шолган (Sorex minutissimus, Zimmermann, 1780), Наттерер төн күбәләге (Myotis nattereri, Kuhl, 1817), мыеклы төн күбәләге (Myotis mystacinus, Kuhl, 1819), Брандт төн күбәләге (Myotis brandti, Eversmann, 1845), Бөя төн күбәләге (Myotis dasycneme, Boie, 1852), су төн күбәләге (Myotis daubentoni, Kuhl, 1817), озын колаклы көрән ярканат (Plecotus auritus, Linnaeus, 1758), гигант кичке ярканат (Nyctalus lasiopterus, Schreber, 1780), кәрлә ярканат (Pipistrellus pipistrellus, Schreber, 1774), зур урман ярканаты (Pipistrellus nathusii Keyserling, Blasius, 1839), төньяк ярканаты (Eptesicus nilssoni Keyserling, Blasius, 1839), ике төсле ярканат (Vespertilio murinus, Linnaeus, 1758), ак куян (Lepus timidus, Linnaeus, 1758), гади очкалак (Pteromys volans, Linnaeus, 1758), Азия борындыгы (Tamias sibiricus, Laxmann, 1769), тимгелле йомран (Citellus suslicus, Guldenstaedt, 1770), урман төнгелеге (Dryomys nitedula, Pallas, 1778), бакча төнгелеге (Eliomys quercinus, Linnaeus, 1766), полчок (Myoxus glis, Linnaeus, 1766), чикләвек төнгелеге (Muscardinus avellanaruis, Linnaeus, 1758), дала тычканчыгы (Sicista subtilis, Pallas, 1773), урман тычканчыгы (Sicista betulina, Pallas, 1779), Эверсман әрләне (Allocricetulus eversmanni, Brandt, 1859), соры

әрлән (Cricetulus migratorius, Pallas, 1770), дала соры тычканы (Lagurus lagurus, Pallas, 1773), зур кушаяк (Allactaga major, Kerr, 1792), кызыл кыр тычканы (Myodes rutilus, Pallas, 1779), көрән аю (Ursus arctos, Linnaeus, 1758), ташлык сусары (Martes foina, Erxleben, 1777), Европа чәшкесе (Mustela lutreola, Linnaeus, 1761), кама (Lutra lutra, Linnaeus, 1758).

Татарстан Республикасы территориясендә саклана торган кошларга түбәндәгеләр керә:

Кара бүксәле күл кошы (Gavia arctica, Linnaeus, 1758), кызыл муенлы поганка (Podiceps auritus, Linnaeus, 1758), соры яңаклы поганка (Podiceps grisegena, Boddaert,1783), зур күлбога (Botaurus stellaris, Linnaeus, 1758), кечкенә күлбога (Ixobrychus minutus, Linnaeus, 1766), зур ак челән (Egretta alba, Linnaeus, 1758), кара ләкләк (Ciconia nigra, Linnaeus, 1758), кызыл бүксәле диңгез казы (Rufibrenta ruficollis, Pallas, 1769), соры каз (Anser anser, Linnaeus, 1758), чыелдык (Anser erythropus, Linnaeus, 1758), ысылдавык аккош (Cygnus olor, Gmelin, 1789), кыйгак аккош (Cygnus cygnus, Linnaeus, 1758), кызыл үрдәк (Tadorna ferruginea, Pallas, 1764), балыкчы карчыга (Pandion haliaetus, Linnaeus, 1758), гади шөпшәашар (Pernis apivorus, Linnaeus, 1758), кыр карчыгасы (Circus cyaneus, Linnaeus, 1766), дала карчыгасы (Circus macrourus, S. G. Gmelin, 1771), болын карчыгасы (Circus pigargus, Linnaeus, 1758), елан ашаучы кош (Circaetus gallicus, Gmelin, 1788), кәрлә бөркет (Hieraaetus pennatus, Gmelin, 1788), зур бөркетсыман кош (Aquila clanga, Pallas, 1811), кабер кошы (Aquila heliaca, Savigny, 1809), бөркет (Aquila chrysaetos, Linnaeus, 1758), ак койрыклы диңгез бөркете (Haliaetus albicilla, Linnaeus, 1758), шоңкар (Falco rusticolus, Linnaeus, 1758), балобан (Falco cherrug, Gray, 1834), сапсан (Falco peregrinus, Tunstall, 1771), дербник (Falco columbarius, Linnaeus, 1758), ягылбай (Falco vespertinus, Linnaeus, 1766), гади торымтай (Falco tinnunculus, Linnaeus, 1758), дала торымтае (Falco naumanni, Fleischer, 1818), соры торна (Grus grus, Linnaeus, 1758), пастушок (Rallus aquaticus, Linnaeus, 1758), камыш чыпчыгы (Gallinula chloropus, Linnaeus, 1758), шөлди-саескан (Haematopus ostralegus, Linnaeus, 1758), зур улит (Tringa nebularia, Gunnerus, 1767), травник (Tringa tetanus, Linnaeus, 1758), поручейник (Tringa stagnatilis, Bechstein, 1803), зур кроншнеп (Numenius arquata, Linnaeus, 1758), зур шөлди (Limosa limosa, Linnaeus, 1758), кара башлы шаркылдык (Larus ichthyaettus, Pallas, 1773), кече акчарлак (Lams minutus, Pallas, 1776), кече диңгез акчарлагы (Sterna albifrons, Pallas, 1764), клинтух (Columba oenas, Linnaeus, 1758), гади урман күгәрчене (Streptopelia turtur, Linnaeus, 1758), ак ябалак (Nyctea scandiaca, Linnaeus, 1758), байгыш (Bubo bubo, Linnaeus, 1758), колаклы ябалак (Asio otus, Linnaeus, 1758), саз ябалагы (Asio flammeus, Pontoppidan, 1763), кечкенә ябалак (Otus scops, Linnaeus, 1758), чырайсыз йонлач аяклы ябалак (Aegolius funereus, Linnaeus, 1758), чырайсыз йорт ябалагы (Athene noctua, Scopoli, 1769), чырайсыз чыпчык ябалагы (Glaucidium passerinum, Linnaeus, 1758), карчыга ябалагы (Surnia ulula, Linnaeus, 1758), соры ябалак (Strix aluco, Linnaeus, 1758), озын койрыклы соры ябалак (Strix uralensis, Pallas, 1771), гади төн күгәрчене (Caprimulgus europaeus, Linnaeus, 1758), күк карга (Coracias garrulus, Linnaeus,

1758), гади кыштуар (Alcedo atthis, Linnaeus, 1758), һөдһөд (Upupa epops, Linnaeus, 1758), яшел тукран (Picus viridis, Linnaeus, 1758), чал тукран (Picus canus, Gmelin, 1788), өч бармаклы тукран (Picoides tridactylus, Linnaeus, 1758), соры соркопут (Lanius excubitor, Linnaeus, 1758), әрбет чыпчыгы (Nucifraga caiyocatactes, Linnaeus, 1758), зәңгәр чыпчык (Parus cyanus, Pallas, 1770).

## 3. Татарстан Республикасыың социаль-икътисадый сыйфатламасы

### 3.1. Татарстан Республикасы территорияләре административ бүленеше карта-схемасы

Беркетелгән һәм һәркем файдалана ала торган аучылык биләмәләренең, шулай ук аучылык ресурслары яши торган, ләкин аучылык биләмәләренә кертелмәгән башка территорияләрнең Татарстан Республикасы буенча урнашуы төбәкнең административ бүленеше карта-схемасында күрсәтелгән (1 нче кушымта). Карта-схема аучылык биләмәләре, аерым саклана торган табигать территорияләре турында мәгълүматны исәпкә алып эшләнде һәм аңа зарури топография катламнары – рельеф, үсемлекләр һ.б. – керә.

### 3.2. Татарстан Республикасында аучылар саны турында мәгълүмат

Татарстан Республикасында аучылык прессы, кагыйдә буларак, җирле аучылар хисабыннан формалаша, бу исә республикада чит ил һәм төбәкара аучылык туристлыгының үсмәвенә бәйле.

Аучылык билетларының ике варианты күздә тотыла: әгъзалык аучылык билеты һәм бердәй федераль үрнәктәге аучылык билеты. Шул ук вакытта ауга рөхсәт бирүче таныклык булып бары бердәй федераль үрнәктәге аучылык билеты гына тора. Шулай итеп, аучының хокукый статусы дәүләт аучылык билеты булуга бәйле («Ау турында» законның 20 статьясы).

Бердәй федераль үрнәктәге аучылык билетлары республикада вәкаләтле дәүләт органы – Татарстан Республикасының хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм файдалану идарәсе тарафыннан бирелә. Әгъзалык аучылык билетлары гражданнарга аучыларның тиешле иҗтимагый оешмалары тарафыннан бирелә. Бердәй аучылык билеты бирелгәндә, әгъзалык аучылык билеты калдырыла һәм иҗтимагый оешмада торучыларга төрле, шул исәптән икътисадый ташламалар бирә ала торган әлеге оешмада гражданның әгъза булуын раслый торган документ булып тора.

Бердәм федераль үрнәктәге аучылык билетлары 2011 елның 1 июленнән бирелә. 2020 елның 1 декабренә Татарстан Республикасында мондый төрдәге 59 152 билет бирелгән. «Ау турындагы» Законның 20 статьясы нигезендә хокукый затның яки шәхси эшмәкәрнең хезмәт шартнамәсе яисә граждан-хокукый шартнамә нигезендә ау яки аучылык ресурсларын саклау белән бәйле вазыйфаларын үти торган хезмәткәре аучыга тиңләнә. Хәзерге вакытта Татарстан Республикасы территориясендә аучылык өлкәсендә эшли торган

Иң күп аулана торган кыйммәтле мехлы җәнлекләр арасында төлке икенче урынны алып тора. Соңгы биш елда төлкене аулау 3000–4400 башка кадәр җитә. Карала торган чорда иң күбе 2019–2020 елларда 4 412 баш ауланган, иң азы 2016–2017 елларга туры килә, бу вакытта 3 149 җәнлек ауланган. Төлкегә ау бернинди көнлек һәм сезон нормалары буенча да билгеләнми, чөнки әлеге төр

республикада бик күп таралган. Моннан тыш, төлке котыру, корчаңгы кебек куркыныч авыруларны таратучы булып тора, нарат урманындагы киек җанварларны, соры куянны һәм ак куянның баш санына йогынты ясый. Шул рәвешле, әлеге төрне аулау күләме табигый рәвештә, урманнардагы җәнлекләрнең һәм аучыларның санына карап, җайга салына.

90 нчы таблицада төлкене аулауның гомуми күләмен төрле муниципаль районнар буенча бүлү мәгълүматлары китерелә.

90 нчы таблица

Төлкене аулауның гомуми күләмен Татарстан Республикасы территориясе буенча бүлү

| Т/с | Муниципаль район | Еллар, баш саны | | | | | Уртача еллык ау күләме, баш саны |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2015–2016 | 2016–2017 | 2017–2018 | 2018–2019 | 2019–2020 | |
| 1 | Әгерже | 17 | 57 | 57 | 56 | 67 | 50,8 |
| 2 | Азнакай | 749 | 103 | 116 | 117 | 224 | 261,8 |
| 3 | Аксубай | 115 | 101 | 125 | 90 | 32 | 92,6 |
| 4 | Актаныш | 13 | 0 | 2 | 11 | 11 | 7,4 |
| 5 | Алексеевск | 78 | 124 | 116 | 172 | 207 | 139,4 |
| 6 | Әлки | 93 | 68 | 256 | 221 | 172 | 162 |
| 7 | Әлмәт | 161 | 107 | 239 | 140 | 112 | 151,8 |
| 8 | Апас | 62 | 140 | 90 | 121 | 104 | 103,4 |
| 9 | Арча | 53 | 56 | 71 | 78 | 105 | 72,6 |
| 10 | Әтнә | 21 | 12 | 0 | 0 | 12 | 9 |
| 11 | Баулы | 113 | 223 | 73 | 169 | 82 | 132 |
| 12 | Балтач | 74 | 62 | 99 | 144 | 90 | 93,8 |
| 13 | Бөгелмә | 125 | 44 | 68 | 36 | 119 | 78,4 |
| 14 | Буа | 94 | 116 | 151 | 58 | 89 | 101,6 |
| 15 | Югары Ослан | 41 | 76 | 52 | 80 | 85 | 66,8 |
| 16 | Биектау | 85 | 111 | 91 | 60 | 91 | 87,6 |
| 17 | Чүпрәле | 38 | 89 | 57 | 69 | 97 | 70 |
| 18 | Алабуга | 60 | 12 | 56 | 42 | 36 | 41,2 |
| 19 | Зәй | 89 | 82 | 112 | 77 | 105 | 93 |
| 20 | Зеленодольск | 71 | 69 | 40 | 66 | 47 | 58,6 |
| 21 | Кайбыч | 22 | 55 | 82 | 57 | 52 | 53,6 |
| 22 | Кама Тамагы | 56 | 20 | 48 | 35 | 19 | 35,6 |
| 23 | Кукмара | 0 | 0 | 11 | 10 | 0 | 4,2 |
| 24 | Лаеш | 33 | 45 | 56 | 88 | 105 | 65,4 |
| 25 | Лениногорск | 133 | 111 | 127 | 121 | 203 | 139 |
| 26 | Мамадыш | 59 | 89 | 85 | 87 | 69 | 77,8 |
| 27 | Менделеевск | 63 | 83 | 86 | 68 | 69 | 73,8 |
| 28 | Минзәлә | 30 | 24 | 53 | 103 | 249 | 91,8 |
| 29 | Мөслим | 62 | 33 | 50 | 85 | 36 | 53,2 |
| 30 | Түбән Кама | 96 | 119 | 136 | 154 | 110 | 123 |
| 31 | Яңа Чишмә | 45 | 41 | 19 | 32 | 154 | 58,2 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 32 | Нурлат | 91 | 65 | 154 | 176 | 122 | 121,6 |
| 33 | Питрәч | 39 | 26 | 55 | 39 | 31 | 38 |
| 34 | Балык Бистәсе | 107 | 52 | 22 | 38 | 73 | 58,4 |
| 35 | Саба | 42 | 104 | 206 | 96 | 96 | 108,8 |
| 36 | Сарман | 121 | 77 | 214 | 214 | 251 | 175,4 |
| 37 | Спас | 36 | 86 | 97 | 150 | 130 | 99,8 |
| 38 | Тәтеш | 131 | 122 | 429 | 184 | 112 | 195,6 |
| 39 | Тукай | 157 | 94 | 152 | 112 | 173 | 137,6 |
| 40 | Теләче | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 41 | Чирмешән | 161 | 56 | 145 | 213 | 184 | 151,8 |
| 42 | Чистай | 199 | 150 | 138 | 216 | 262 | 193 |
| 43 | Ютазы | 37 | 45 | 67 | 60 | 25 | 46,8 |

Куяннарны аулау күләмнәре белән чагыштырганда, төлке аулау күләмнәре Татарстан Республикасы районнары буенча тигезрәк бүленгән, бу 32 нче рәсемдә ачык күренә.




32 нче рәсем. Төлкегә уртача еллык ау күләмен Татарстан Республикасы муниципаль районнары территорияләре буенча бүлү

Иң күп төлкеләр Азнакай, Тәтеш һәм Чистай районнарында табыла. Иң азы- Актаныш, Әтнә һәм Кукмара районнарында. Мондый табыш күрсәткечләре әлеге районнарда төрнең күп булуы күрсәткечләренә туры килә. Шулай итеп, Азнакай районында төлкеләрнең саны Кукмара районына караганда уртача 11 тапкырга күбрәк.

Су күсесе Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларын (кыйммәтле мехлы җәнлекләрнең) аулау буенча өченче урында тора. Әлеге төрне аулау динамикасында су күсесен аулауның кисәк кенә артып китүе дә, шул ук вакытта кисәк кенә кимүе дә күзәтелә (33 нче рәсем).




33 нче рәсем. 2013–2020 елларда Татарстан Республикасында су күсесен аулау динамикасы

Күрсәткечләрдәге мондый кискен үзгәрешләрне без барыннан да элек мәгълүматларны тиешле күләмдә исәпкә алмау белән аңлатабыз. Су күсесенә ауның зур күләмдә алып барылуына да карамастан, ул республиканың нибары берничә районында гына аулана. Ауның гомуми күләменең 50 %ы Буа һәм Питрәч районыннарына туры килә, Балтач, Лаеш , Балык Бистәсе һәм Тәтеш районнарында су күсесенә ау аз күләмдә һәм даими түгел. Ауның шушы рәвешле тигезсез бүленеше районнарның табигый шартлары белән дә, республика территориясендә су күсесенең таралу дәрәҗәсе белән дә бәйле.

Киек кошлар.

Соңгы елларда Татарстан Республикасының Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе хисапларында киек кошларның аерым төрләре таксономик төркемнәргә берләшә (үрдәкләр, казлар, шөлдиләр). Республикада барлыгы уртача 16 000 киек кош аулана. Аларның 75 %ын үрдәкләрнең төрле төрләре тәшкил итә. Башка төрләрне аулар күп түгел.

Татарстан Республикасында киек кошларның төркемнәргә бүленеше 91 нче таблицада һәм 34 нче рәсемдә ачык күрсәтелгән.

91 нче таблица

Татарстан Республикасында киек кошларга уртача еллык ау

| Төре | Уртача еллык ау күләме, баш саны | Гомуми ау күләме, % |
|---|---|---|
| Шөлдиләр (төрен күрсәтмичә) | 91 | 0,6 |
| Үрдәкләр (төрен күрсәтмичә) | 12333 | 75,4 |
| Казлар (төрен күрсәтмичә) | 2654 | 16,2 |
| Урман киек кошлары (төрен күрсәтмичә) | 1240 | 7,6 |
| Күгәрченнәр (төрен күрсәтмичә) | 31 | 0,2 |
| Барлыгы | 16349 | 100 |

Тулаем алганда, киек кошларны аулау динамикасын анализлау вакытында аучылык күзәтчелеге органнарының аучылык ресурслары күләменә зур тәэсирен билгеләп үтәргә кирәк, ул даими рәвештә киек кошларның теге яки бу төренә ауны тыюда чагыла. 2019 елның җәйге-көзге-кышкы сезоны һәм 2020 елның язгы сезоны чорында барлык аучылык җир-суларында суерны һәм көртлекне аулау тыелды. Бу чараларның барысы да республикадагы киек кошларның баш санын арттыру максатында, аучылык биләмәләрендә аерым төрләрнең аз тыгызлыкта яшәвенә бәйле рәвештә күрелде.




34 нче рәсем. Татарстан Республикасы территориясендә аулана торган аучылык ресурсларының (кошларның) төркемнәр буенча сан нисбәте

Үрдәкләр арасында кыр үрдәге зур әһәмияткә ия, ул үрдәкләрне аулауның гомуми күләменең 42 % тәшкил итә, шул ук вакытта 57 % «төре күрсәтелмәгән» үрдәкләргә туры килә. Әлеге төркемдә дә кыр үрдәгенең булуы мөмкин. Үрдәкләрнең безкойрык, чүрәкәй үрдәк, киң борынлы үрдәк, сыбызгы-үрдәк кебек калган төрләре бик сирәк очрый.

Җирле аучылар казларның соры каз, ындыр казы һәм ак маңгайлы каз кебек төрләрен аулый. Шул ук вакытта казларның «төре күрсәтелмәгән» категорияләре 57 % тәшкил итә. Бер сезонда уртача 2 300 тирәсе төрле төр каз аулана.

Урман киек казларына суер, көртлек, боҗыр һәм тәллетәвеч керә, алар киек кошларга ауның гомуми күләменнән 7,6 % ны тәшкил итә. Шул ук вакытта ау күләменең зур өлеше тәллетәвечкә туры килә – 90 %. Боҗырга ау махсус оештырылмый, ә көртлеккә ау республиканың барлык муниципаль районнарында диярлек бары тик язгы чорда гына рөхсәт ителгән. Аерым чорларда, мисал өчен, 2019–2020 еллардагы ау сезонында суерга ау барлык аучылык җиләмәләрендә тыелган иде.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларыннан файдалануны анализлау күрсәткәнчә, иң еш аулана торган аучылык ресурсларына соры куян, төлке, кабан дуңгызы һәм киек су кошлары керә. Башка төрдәге тәллетәвечләр һәм шөлдиләр, урман киек җанварлары, сусар, янутсыман эт һәм аучылык ресурсларының башка төрләре, кагыйдә буларак, аларга махсус ау оештырмыйча, аучылык ресурсларының төп төрләрен аулаганда гына аулана.

Аучылык биләмәләрен оештырганда һәм аларны эшләткәндә төп аучылык ресурсларын саклауга һәм яңадан торгызуга аеруча зур игътибар бирелергә тиеш. Бу ресурслар әһәмиятле социаль роль дә башкара, чөнки нәкъ менә аучылык объектларның күплеге хисабына төбәк халкының актив ялга ихтыяҗлары канәгатьләндерелә.

Аучылык ресурслары күләмнәрен фәнни нигездә мониторинглау республикада даими рәвештә гамәлгә ашырылырга тиеш, чөнки һәр төрне аулау күләме һәм аларның күпьеллык динамикасы хайваннарның фактагы санын билгеләүче әһәмиятле күрсәткеч булып тора, аларның баш санын исәпкә алу буенча мәгълүматларга өстәмә буларак хезмәт итә. Махсус исәпкә алынмый торган күчмә төрләрне аулауга мониторинг аларның таралышының гомуми торышын мониторинглауның нәтиҗәле инструменты булып тора.

## 6. Аучылык биләмәләреннән рациональ файдалануны оештыру чаралары

### 6.1. Аучылык хуҗалыгын үстерү буенча төп юнәлешләр һәм чаралар

Аучылык хуҗалыгы матди җитештерү өлкәсе булып тора, ул халыкның ауга карата, аның белән бәйле башка эшләргә карата ихтыяҗларын тәэмин итү өчен аучылык хайваннарын, аучылык хуҗалыгы продукциясен һәм башка төрле тиешле продукцияне аучылык җирләрен саклау һәм яхшырту һәм башка (авыл хуҗалыгы һәм урман хуҗалыгы) тармаклардагы мәнфәгатьләрне исәпкә алу нигезендә яңадан җитештерү һәм алардан тотрыклы файдалану гамәлгә ашырыла. Аучылык ресурслары һәм аучылык ресурсларының яшәү тирәлеге булган аучылык биләмәләре аучылык хуҗалыгының нигезен тәшкил итә. Шуңа күрә аларны саклауга һәм алардан рациональ файдалануны оештыруга зур игътибар бирелә.

Соңгы 10 елда Татарстан Республикасы аучылык хуҗалыгының функцияләвен оештыру дәрәҗәсен һәм үзенчәлекләрен анализлау нәтиҗәсендә аучылык

тармагының динамикалы үсеп китүен toткарлый торган аеруча актуаль проблемаларны билгеләп үтәргә мөмкин:

аучылык хуҗалыгына инвестиция кертүнең күләме аз булуы;

аучылык инфраструктурасы үсешенең түбән дәрәҗәдә булуы, шуның нәтиҗәсендә читтән керә торган аучылык туризмы үсеп китә алмау;

ау оештыру белән бәйле күрсәтелгән хезмәтләрнең түбән сыйфатлы һәм төрләренең аз булуы;

башкарыла торган биотехник (ресурсларны күчерү, ерткычларны контрольдә тоту, аучылык җирләрендәге ашату һәм саклау сыйфатламаларын яхшырту) чараларның күләме аз булуы;

аучылык белән шөгыльләнүчеләр тарафыннан аучылык ресурсларын саклауның нәтиҗәле системасы булмау;

аучылык ресурсларының янгыннарда һәм авыл хуҗалыгы эшләрен башкарганда (агулы химикатларны, киң колачлы һәм югары тизлектәге авыл хуҗалыгы техникасын кулланганда) һәлак булуы.

Югарыда атап үтелгән проблемаларны чишүне аучылык ресурсларының яшәү тирәлегеннән файдалану, тармакны оештыру һәм үстерүнең стратегик планлаштыру нигезендә гамәлгә ашырырга кирәк.

Түбәндә Татарстан Республикасында аучылык ресурсларыннан һәм аучылык биләмәләреннән рациональ файдалануны оештыру буенча планлаштырылган чаралар күрсәтелә:

аучылык ресурсларын күчерү юлы белән яшәү тирәлеген, үрчү шартларын, туплану урыннарын саклау;

Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән югалып баручы төрләрнең яшәү урыннарын картага төшерү һәм саклап калу;

аучылык ресурсларының таралышында бара торган үзгәрешләрне үз вакытында ачыклау; аучылыкны һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендә карарлар кабул итү өчен дәүләт органнарына республикадагы аучылык ресурсларының торышы, баш саны динамикасы, таралышы турында тулы, төгәл мәгълүматлар бирү;

электр челтәрләрен җәелдерүнең проектларына һәм планнарына (схемаларына) экологик экспертизалар үткәргәндә конкрет экологик шартларда кошларның электрүткәргеч линияләр җайланмалары белән үзара бәйленеше төрен (орнитоценозлар структурасы үзгәрүне, тәүлекле, сезонлы һәм күпьеллык режим динамикаларында аларның ландшафт һәм электр челтәрләре белән бәйләнешен; миграция коридорларының һәм кошларның туплану ураннарының булуын, һәм шулай ук электрүткәргеч линияләр урнашу урыннарында кошларның үз-үзләрен тотышына идарә итү мөмкинлеген) фаразлау;

кыргый җәнлекләргә китерелгән зыян китермәү һәм/яки әлеге зыянны киметү максатларында авыл хуҗалыгы предприятиеләренең химик һәм агротехник чаралар куллануга, терлек көтүгә таләпләрне һәм шартларны үтәүләренә карата системалы мониторинг һәм даими контроль кертү һәм гамәлгә ашыру; теге яки бу пестицидларны куллануның урынлы булуы турындагы мәсьәләне хәл иткәндә тере табигатькә (корткычларны юк итү өчен нәтиҗәле һәм кешелек өчен агулы булудан тыш) китерелгән зыянны исәпкә алу;

урман һәм аучылык хуҗалыкларының үзара эшчәнлеге, кисентеләрнең күләмнәрен һәм ысулларын, урман бүлемтекләре мәйданнарын ачыклаганда аучылык хуҗалыгы мәнфәгатьләрен исәпкә алу; урманнан файдалануның аучылык ресурслары баш санына карата тискәре йогынтысын киметү;

кыйммәтле азык булып торучы яшь агачларның торышын, мәйданнары күләмнәрен тикшереп торуны урман яңарту практикасына кертү;

аучылык биләмәләренең азык, саклау, оя кору һәм башка төрле (вак куакларны саклау, куышлы агачларны калдыру һ.б.) кирәкле булган үзенчәлекләрен саклау буенча урман хуҗалыгы предприятиеләре тарафыннан кагыйдәләрнең һәм нормаларның үтәлүен тикшереп тору;

кызыксынган оешмалар тарафыннан кулланыла торган технологияләргә зыян китерүче кыргый хайваннарны өркетү һәм читләштерү ысулларын кертү буенча чаралар күрү;

кыргый җәнлекләр өчен куркыныч тудыручы этләрне һәм башка төрле хайваннарны ирекле яки бәйдән башка йөртүне бетерү буенча барлык мөмкин булган чараларны күрү.

Аучылык җирләреннән рациональ файдалануны оештыру буенча юнәлешләр:

аучылык җирләрен беркетүнең аукцион принципларын үтәү иң сыйфатлы аучылык биләмәләрен аларның инфраструктурасын үстерү һәм аларны оештыру буенча иң зур финанс мөмкинлекләренә ия булган юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә тапшыру мөмкинлеген бирәчәк. Шул ук вакытта (аучылык биләмәләренең) аукцион лотларын формалаштыруга карата фәнни-дәлилле якын килү мөһим, чөнки формалаштырыла торган аучылык урыннары берникадәр критерийларга (мәйданының идарә ителүчәнлеге, җитәрлек булуы, күптөрлелек һ.б.) туры килергә тиеш, бу исә булачак аучылык хуҗалыкларын үстерүнең уңышлы башлангычы булып тора.

аучылык җирләренең җитештерүчәнлеген арттыру буенча чаралар комплексын эшләү. Аучылык җирләрен төзекләндерү аучылык оештыруның эчке хуҗалык документларында һәм килешүләрдә күрсәтелгән таләпләр нигезендә ау хуҗалыгы турында килешү төзегән юридик затлар һәм гражданнар тарафыннан үткәрелергә тиеш;

аучылык инфраструктурасын оештыруның мәҗбүрилеге иң яхшы аучылык биләмәләрен (эре урман массивлары, сулыклы-сазлыклы җирләр) файдалануга алучы арендаторлар белән төзелә торган ау хуҗалыгы килешүләрендә беркетелергә тиеш;

эшчәнлекне ял итү өчен махсуслаштыру. Һәвәскәр һәм спорт авын үстерү буенча мөмкин булган юнәлешләр арасында өстенлекле рәвештә ганимәт аучылыгын һәм аучылык туризмын үстерү максатчан һәм планлаштырыла торган юнәлешләр булып тора. Татарстан Республикасы шартларында кабан дуңгызы, поши, көртлек туристлар иң күп аулый торган ресурслар булып тора. Ләкин бу Татарстан Республикасы территориясендә ауның башка төрләрен үстерүне дә күз уңыннан ычкындырмый;

аучылык белән катнаш эшчәнлек юнәлешләрен – ау этләрен асрау, ату-аучылык спорты, таксидермия, аучылык продукциясен эшкәртүне үстерү;

ау хайваннарын вольерларда үрчетү. Татарстан Республикасы шартларында тояклы хайваннарны вольерларда үрчетүнең актуальлеге аларга карата гарантияле ау тәэмин итү өчен, тиз арада вольер төркемчәләрен оештыру, ә димәк, өстәмә продукция һәм керемнәр алу өчен шартлар тудырылырга мөмкин булуы белән аңлатыла. Вольерлардагы хайваннар аларның хуҗалары милеге булып санала һәм аларны аулау вакытын һәм күләмен хуҗа үзе билгели. Аларны ел дәвамында ауларга мөмкин, бу исә әлеге тармакка карата тагын да зуррак кызыксындыру уята;

аучылык ресурсларын саклауның, үрчетүнең һәм алардан рациональ файдалануның хокукый һәм икътисади механизмын тәэмин итү. Аучылык ресурсларыннан законсыз һәм рациональ булмаган файдалануның икътисадый яктан отышсыз булуы өчен шартлар тудыру;

югарыда күрсәтелгән эшчәнлекне һәм фәнни күрсәтмәләрне анализлау нигезендә аучылык ресурсларын саклау, үрчетү һәм алардан рациональ файдалану буенча идарәче карарлар кабул итү, аучылык җирләрендә ауны оештыру, аучылык ресурсларын мониторинглау һәм аларның кадастрын алып бару;

аучылык хуҗалыгында кадрлар сәясәтен гамәлгә ашыру, аучылык хуҗалыгы хезмәткәрләренең тәҗрибә алмашу һәм квалификациясен күтәрү буенча семинарлар үткәрүгә булышлык күрсәтү;

аучылык ресурсларын саклау, үрчетү һәм алардан рациональ файдалануны оештыру мәсьәләләрен хәл итүдә ау хуҗалыгы оешмаларның мөстәкыйльлеген арттыру;

әлеге өлкәдә норматив-хокукый базаны камилләштерү һәм арендаторлар белән ау хуҗалыгы идарәче органнарның координацияләнгән эш-гамәлләре.

### 6.2. Татарстан Республикасындагы аучылык биләмәләренең ау мөмкинлекләре

Аучылык биләмәләренең ау мөмкинлекләре дигәндә бер көндә яисә бер сезонда бу аучылык хуҗалыгында булып китә алган аучылар саны күздә тотыла.

Аучылык биләмәләренең территориаль мөмкинлекләре дә, биологик (фактик) мөмкинлекләре исәпләнелә. Әгәр дә аучылык биләмәләренең территориаль һәм биологик мөмкинлекләре бер төрле булмаса, ауны планлаштырганда нигез итеп аларның сан ягыннан кимрәген алырга кирәк.

Хуҗалыкның территориаль мөмкинлеге – ул аның территориясендә бер үк вакытта бер-берсенә комачауламый һәм куркынычсызлык техникасын бозмый ауга чыга алучы аучылар саны. Конкрет ау төре өчен көндезге вакытта ау мөмкинлеге алар яшәү өчен яраклы аучылык биләмәләре мәйданын бер кв метр мәйданда ауга чыга алырлык аучыларның максималь санына бүлү юлы белән исәпләп чыгарыла. Әлеге төр ау мөмкинлеге аучылык биләмәләре мәйданына һәм ауның төренә, ау өчен аучылык биләмәләренең бөтен җирен бер үк вакытта файдалану мөмкинлегенең процентларда күрсәткеченә, аучылык сезонының дәвамлылыгына һәм теге яки бу ау төрләрендә аучыларның бер кв метр мәйданда ауга чыга алу мөмкинлегенә бәйле, ләкин киек җанварларның санына бәйле түгел. Аучылык ресурслары яшәү өчен яраклы аучылык биләмәләре территориясендә берьюлы ауга чыгу киек җанварларның яшәү шартларына тискәре йогынты ясый, еш кына аны әлеге аучылык хуҗалык чикләреннән күчеп китәргә мәҗбүр итә. Шуңа да аучылык

биләмәләренең барлык территориясендә берьюлы ауга чыгу бары тик 60-70% мәйданда гына проектланырга тиеш, чөнки бу хуҗалыкның территориаль мөмкинлеген күпкә киметә.

Территориаль мөмкинлеге даими зурлык булып санала, ул аучылык биләмәләренең төренә һәм аларның мәйданына бәйле. Ауның төп төрләре өчен территориаль мөмкинлек 92 нче таблицада китерелә.

Дала һәм кыр киекләрен аулау.

Әлеге аучылык ресурслары кырларда аулана, алар Татарстан Республикасында иң киң таралган аучылык биләмәләре төрләре булып тора. Татарстан Республикасы территориясе өчен әлеге аучылык биләмәләрнең ау мөмкинлеге бер аучыга 25 га җир каралган.

Сазлык-болын киекләрен аулау.

Әлеге ау төре уратып алып, яшеренеп утырган җирдән, ау кошлары, ау этләре ярдәмендә башкарыла. Аулау өчен чынлыкта аучылык биләмәләренең бөтен өлеше түгел, ә нибары бер өлеше генә яраклы булу шартын исәпкә алырга кирәк. Шул рәвешле, әлеге ау төрләрен башкару өчен бер аучыга 25 га мәйдан күләмендә территориаль ау мөмкинлеге нормасын киңәш итәргә мөмкин.

Урман киекләрен «гөрдердәү» чорында аулау.

Суер һәм көртлекне «гөрдердәү» чорында аулаганда мәйдан нормаларын билгеләү максатка ярашсыз булып тора. Урман киекләрен «гөрдердәү» чорында аулау буенча аучылык җирләренең ау мөмкинлеге ауланачак кошларның санына тигез.

Тәлләтәвечкә язгы ау.

Бары тик «ата тәлләтәвечнең билгеле бер очышы» вакытында гына ауга чыгу күздә тотыла, шуңа да исәпләүне бары тик тоташ утыртмалар (табигый һәм ясалма) мәйданында гына алып барырга кирәк, бу хуҗалык эчендә аучылыкны оештыру вакытында билгеләнә. Аткан вакытта куркынычсызлыкны тәэмин итәрлек ераклыгын исәпкә алып, әлеге ау төрендә территориаль ау мөмкинлеге бер аучыга кимендә 25 га мәйдан тәкъдим ителә.

Казларга язгы ау.

Ау авыл хуҗалыгы биләмәләрендә башкарыла. Хуҗалык эчендә ауны оештырганда казларны даими ашату өчен кулланыла торган авыл хуҗалыгы биләмәләренең фактагы мәйданын билгеләргә кирәк. Ау мөмкинлеген исәпләү өчен казлар даими яши торган авыл хуҗалыгы биләмәләре мәйданын күздә тотарга кирәк. Бер аучыга ау өчен яраклы булган 25 гектардан да ким булмаган аучылык биләмәләрен исәпләргә тәкъдим ителә.

Кыйммәтле мехлы җәнлекләрне һәм куяннарны аулау.

Кагыйдә буларак, әлеге ау төре өчен аучылык биләмәләренең барлык төрләре дә диярлек файдаланыла. Шул ук вакытта ау вакытында зур ераклыкларда

куркыныч тудыручы аеруча зур ядрә кулланылырга мөмкин. Ау күп очракта кырларда алып барыла, ә бу исә ядрәләр өчен бернинди тоткарлык булмавын аңлата. Әлеге төр ау өчен ау мөмкинлеге нормаларын планлаштырганда моны да исәпкә алырга кирәк. Кыйммәтле мехлы җәнлекләргә һәм куянга җәяүле ау вакытында индивидуаль ау маршрутының уртача озынлыгы югары була. Санап үтелгән нигезләрне исәпкә алып, төрле ысуллар кулланып индивидуаль ау вакытында кыйммәтле мехлы җәнлекләр өчен хас аучылык биләмәләрен бер аучыга кимендә 400 гектардан исәпләргә кирәк. Әгәр дә хуҗалык аучысы җитәкчелегендә коллектив оешкан төстә ауга чыкса, ау мөмкинлеге нормасы 5 аучыга кадәр төркем өчен 2000 га тәшкил итәчәк.

92 нче таблица

Татарстан Республикасы аучылык биләмәләренең территориаль үткәрү мөмкинлеге

| Т/с | Ау төре | Аучылар составы | Ау өчен яраклы биләмәләр мәйданы нормативы, га | Төр яшәү өчен яраклы мәйдан, га | Мәйданның аны коррекция-ләү коэффи-циентын исәпкә алынган 70% проценты | Көндезге террито-риаль ау мөмкинлеге (кеше саны) |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Пошины уратып алып аулау | 10 аучыдан кимрәк | 1000 | 1366791,3 | 956753,9 | 9568 |
| 2 | Кабан дуңгызын уратып алып аулау | 10 аучыдан кимрәк | 1000 | 1393312,13 | 975318,493 | 9753 |
| 3 | Кыр кәҗәсен уратып алып аулау | 10 аучыдан кимрәк | 1000 | 1857193,66 | 1300035,56 | 13000 |
| 4 | Пошины көзге-кышкы чорда куып аулау | 10 аучыдан кимрәк | 1000 | 1366791,3 | 956753,9 | 9568 |
| 5 | Кабан дуңгызын көзге-кышкы чорда куып аулау | 10 аучыдан кимрәк | 1000 | 1393312,13 | 975318,493 | 9753 |
| 6 | Кыр кәҗәсен көзге-кышкы чорда куып аулау | 10 аучыдан кимрәк | 1000 | 1857193,66 | 1300035,56 | 13000 |
| 7 | Ау этләре белән соры куян аулау | 5 аучыдан кимрәк | 2000 | 4142331,3 | 2899631,91 | 7249 |
| 8 | Ау этләре белән ак куян аулау | 5 аучыдан кимрәк | 2000 | 1366791,3 | 956753,907 | 2392 |
| 9 | Ау этләре белән төлке аулау | 5 аучыдан кимрәк | 2000 | 4142331,3 | 2899631,91 | 7249 |
| 10 | Суерны җәйге-көзге чорда ау этләре белән аулау | 40 аучыдан кимрәк | 1000 | 1299949,31 | 90964,517 | 3639 |
| 11 | Көртлекне җәйге-көзге чорда ау этләре белән аулау | 40 аучыдан кимрәк | 1000 | 1799598,5 | 1259718,95 | 50389 |
| 12 | Кыр киекләрен җәйге-көзге чорда | 40 аучыдан кимрәк | 1000 | 4694456,1 | 3286119,27 | 131445 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | ау этләре белән аулау | | | | | |
| 13 | Җәйге-көзге чорда үрдәкне уратып алып аулау | 40 аучыдан кимрәк | 1000 | 155140,906 | 1085798,63 | 43432 |
| 14 | Үрдәкләрне җәйге-көзге чорда карачкылар белән аулау | 40 аучыдан кимрәк | 1000 | 155140,906 | 1085798,63 | 43432 |
| 15 | Алдавыч үрдәк белән язын аулау | 40 аучыдан кимрәк | 1000 | 155140,906 | 1085798,63 | 43432 |

92 нче таблицада түбәкнең хуҗалык эчендә ауны оештырган вакытта әлеге хуҗалыкның ау мөмкинлеге аучылык өчен яраклы барлык мәйданында исәпләнмәве хисабына киметелү ихтималы булган максималь территориаль ау мөмкинлеге китерелгән.

Аучылык биләмәләренең барлык киек-кош запаслары бу рәвешле исәпләп чыгарылган аучылар санын кабул итәргә әзер түгеллеге ачык күренә. Ау мөмкинлегенең факттагы (ресурс) исәбен, ягъни бар булган киек-кош запаслары нигезендә аулау мөмкинлеге бирерлек аучылар санын исәпләп чыгарырга кирәк. Аучылык ресурсларының һәр төре өчен бер үк хуҗалыкта факттагы ау мөмкинлеге төрле булырга мөмкин, шул ук вакытта ул вакыт узу аучылык ресурслары популяциясенең торышына һәм сан күрсәткечләренә бәйле рәвештә белән үзгәрергә дә мөмкин.

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 2020 елның 25 ноябрендәге 965 номерлы боерыгы нигезләмәләрен исәпкә алып, факттагы ау мөмкинлеген исәпләү аучылык лимиты билгеләнә торган төрләр өчен генә гамәлгә ашырыла. Әлеге төрләр буенча аерым бер хуҗалыкның факттагы минималь ау мөмкинлеге аларның аучылык ресурсларына бүлеп бирелгән квотага тигез.

Лимитлары расланмый торган ау ресурслары өчен аерым бер сезонда аларга ау нормативлары билгеләнми.

### 6.3. Татарстан Республикасы территориясендә аучылык биләмәләре оештыру өчен зоналар бүлеп бирүне планлаштыру турында мәгълүмат

«Ау турында» Законның 7 статьясы 3 пункты нигезендә һәркем файдалана алырлык аучылык биләмәләре Россия Федерациясе субъектының аучылык биләмәләре гомуми мәйданының кимендә егерме процентын тәшкил итәргә тиеш. Беркетелгән яңа аучылык җирләрен планлаштыру файдалануга бирелгән территорияләрдә гомуми файдаланудa булган аучылык биләмәләре белән чагыштырганда, аучылык биләмәләрен саклау һәм биотехник чаралар үткәрү дәрәҗәсе сизелерлек югары булуы белән аңлатыла. Беркетелгән аучылык җирләрендә ау белән шөгыльләнүчеләрнең актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә ау хайваннарының саны сизелерлек арта, бу ау хуҗалыгын алып баруның төп максатларының берсе булып тора да инде.

Һәркем файдалана алырлык аучылык биләмәләре төбәктәге аучылык биләмәләренең гомуми мәйданыннан якынча 33,23% тәшкил итә. Һәркем файдалана алырлык аучылык биләмәләренең бар булган мәйданы киләчәктә ау хуҗалыгы килешүләрен төзү хокукы булган яңа беркетелгән аучылык биләмәләрен аукционнар үткәрү юлы белән планлаштырылырга мөмкинлек бирә.

## 6.4. Аучылык ресурсларын саклау зоналарын бүлеп чыгару турында мәгълүмат

Аучылык ресурсларын саклау максаты белән, аучылык байлыкларын саклау зоналары оештырыла. Ул зоналарда аучылык ресурсларын куллану чикләнә. Җирлектә мондый саклау зоналарын билгеләгәндә, Татарстан Республикасында аучылык белән шөгыльләнүчеләр һәм кызыксынган дәүләт органнары Россия Федерациясенең Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Җирлектә аучылык ресурсларын саклау зоналары чикләрен урнаштыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 6 июлендәге 412 нче номерлы боерыгы нигезләмәләренә таяна. Шуңа бәйле рәвештә, саклау зоналарын бүлгәндә:

җирлектә аучылык ресурсларын саклау зонасының чикләре махсус мәгълүмат билгеләре белән билгеләнгән, аларда аучылык ресурсларын саклау максатларында кертелә торган чикләүләр, аучылык ресурслары өчен саклау зонасы билгеләнә торган аучылык җир-суларының атамасы (башка территория), күрсәтелгән;

махсус мәгълүмати билгеләр аучылык ресурсларын саклау зонасы чикләренең периметры буенча, аучылык байлыкларын саклау зонасына керү (чыгу), кешеләр йөри торган урыннарда, шулай ук аучылык ресурсларын саклау зонасы эчендә урнаштырылган.

Хуҗалык эчендәге корылмаларга ярашлы рәвештә, саклау зоналары түбәндәге аучылык хуҗалыкларында бүлеп бирелде:

Әгерҗе муниципаль районында – «Кызыл бор» аучылык хуҗалыгы;

Азнакай муниципаль районында – «Азнакай» аучылык хуҗалыгы;

Аксубай муниципаль районында:

«Аксубай» аучылык хуҗалыгы;

«Бөркет» аучылык хуҗалыгы;

Актаныш муниципаль районында - «Актаныш» аучылык хуҗалыгы;

Алексеевск муниципаль районында - «7 завод» аучылык хуҗалыгы;

Әлки муниципаль районында - «Көньяк» аучылык хуҗалыгы;

Әлмәт муниципаль районында:

«Ласка» аучылык хуҗалыгы;

«Бута-Чишмә» аучылык хуҗалыгы;

«Кама-Исмәгыйль» аучылык хуҗалыгы;

Апас муниципаль районында - «Апас» аучылык хуҗалыгы;

Арча муниципаль районында – «Үрнәк» аучылык хуҗалыгы;

Әтнә муниципаль районында – «Әтнә» аучылык хуҗалыгы (1 нче участок, 2 нче участок, 3 нче участок);

Баулы муниципаль районында - «Поповский» аучылык хуҗалыгы;

Балтач муниципаль районында - «Төньяк» аучылык хуҗалыгы;

Бөгелмә муниципаль районында:

«Юкә» аучылык хуҗалыгы;
«Бөгелмә» аучылык хуҗалыгы;
Буа муниципаль районында:
«Баек урманчылыгы» аучылык хуҗалыгы;
«Буа» аучылык хуҗалыгы;
Югары Ослан муниципаль районында:
«Югары Ослан» аучылык хуҗалыгы;
«Тәмте» аучылык хуҗалыгы;
Биектау муниципаль районында:
«Глухарь» аучылык хуҗалыгы;
«Аучылык традицияләре» аучылык хуҗалыгы;
Чүпрәле муниципаль районында - «Фазан» аучылык хуҗалыгы;
Алабуга муниципаль районында:
«Свиногорье» аучылык хуҗалыгы (1 нче участок, 2 нче участок, 3 нче участок);
«Алабуга» аучылык хуҗалыгы;
Зәй муниципаль районында:
«Кызыл юл» аучылык хуҗалыгы;
«Зәй» аучылык хуҗалыгы;
«Баграж» аучылык хуҗалыгы;
«Карамалы» аучылык хуҗалыгы;
«Аучы» аучылык хуҗалыгы;
Зеленодольск муниципаль районында:
«Зеленодольск» аучылык хуҗалыгы;
«Зөя» аучылык хуҗалыгы;
Кайбыч муниципаль районында:
«Барс» аучылык хуҗалыгы;
«Кайбыч» аучылык хуҗалыгы;
Кама Тамагы муниципаль районында:
«Кама Тамагы» аучылык хуҗалыгы («Вепрь» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте);
«Кама Тамагы» аучылык хуҗалыгы («Кама Тамагы» аучылык хуҗалыгы җирле иҗтимагый оешмасы)
«Тәмте» аучылык хуҗалыгы;
Кукмара муниципаль районында:
«Лубян» аучылык хуҗалыгы;
«Кукмара» аучылык хуҗалыгы;
Лаеш муниципаль районында:
«Идел-Кама» аучылык хуҗалыгы;
«Никольский» аучылык хуҗалыгы;
«Кама киңлекләре» аучылык хуҗалыгы;
«Янтык» аучылык хуҗалыгы;
Лениногорск муниципаль районында – «Селәүсен» аучылык хуҗалыгы;
Мамадыш муниципаль районында:
«Берсут» аучылык хуҗалыгы;
«Омара» аучылык хуҗалыгы;

«Нократ яры» аучылык хуҗалыгы;
«Урман» аучылык хуҗалыгы;
Минзәлә муниципаль районында:
«Аккош күле» аучылык хуҗалыгы;
«Минзәлә» аучылык хуҗалыгы;
«Яңа Минзәлә» аучылык хуҗалыгы;
Мөслим муниципаль районында:
«Ак Барс» аучылык хуҗалыгы;
«Мөслим» аучылык хуҗалыгы;
Түбән Кама муниципаль районында:
«Иманлек» аучылык хуҗалыгы;
«Ширәмәт» аучылык хуҗалыгы;
«Яңа Чишмә» аучылык хуҗалыгы;
«Сухарев» аучылык хуҗалыгы;
Яңа Чишмә муниципаль районында – «Красновидово» аучылык хуҗалыгы;
Нурлат муниципаль районында:
«Зүзәй» аучылык хуҗалыгы;
«Төрнәс» аучылык хуҗалыгы;
Питрәч муниципаль районында – «Питрәч» аучылык хуҗалыгы;
Питрәч һәм Лаеш муниципаль районнарында – «Салават күпере» аучылык хуҗалыгы;
Балык Бистәсе муниципаль районында – «Кама яры» аучылык хуҗалыгы;
Саба һәм Теләче муниципаль районнарында – «Саба укыту-тәҗрибә урман хуҗалыгы» аучылык хуҗалыгы;
Сарман муниципаль районында – «Сарман» аучылык хуҗалыгы;
Тәтеш муниципаль районында:
«Идел» аучылык хуҗалыгы;
«Тәтеш» аучылык хуҗалыгы;
Тукай муниципаль районында – «Чаллы» аучылык хуҗалыгы;
Чирмешән муниципаль районында – «Чирмешән» аучылык хуҗалыгы;
Чистай муниципаль районында – «Баганалы» аучылык хуҗалыгы (1 нче участок, 2 нче участок).

## 7. Аучылык ресурсларыннан рациональ файдалануны оештыру буенча чаралар

### 7.1. Планлаштырыла торган биотехник чаралар

Аучылык ресурсларын карап тоту һәм аларның санын арттыру буенча чаралар биотехник чаралар булып санала. Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Биотехник чараларның төрен һәм составын, шулай ук аучылык ресурсларын саклап калу максатларында аларны уздыру тәртибен раслау турында» 2010 елның 24 декабрендәге 560 номерлы боерыгы нигезендә аучылык җирләрендә түбәндәге биотехник чаралар үткәрелә:

1. Аучылык ресурсларының үлеменә юл куймау, моның өчен түбәндәгеләр эшләнә:

аучылык ресурсларын законсыз аулауны кисәтү, ә шулай ук аларның яшәү тирәлеген җимерү һәм юк итү;

аучылык байлыкларының санын киметүгә йогынты ясый торган ерткыч хайваннарны бетерү (аучылык байлыкларына кертелгән, ә шулай ук Россия Федерациясенең Кызыл китабына һәм (яки) Россия Федерациясе субъектларының Кызыл китапларына кертелгән хайваннар дөньясы объектларыннан тыш);

транспорт чараларын эксплуатацияләгәндә һәм житештерү процессларын башкарганда, аучылык байлыкларының үлүенә юл куймау;

аучылык җир-суларында аучылык байлыкларын саклау зоналарын булдыру.

2. Аучылык ресурсларын өстәмә тукландыру һәм аларның яшәү тирәлегендәге туклану шартларын яхшырту, ул түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

азык салу;

өстәмә сулыклар булдыру;

азык салу өчен махсус корылмалар төзү;

азык буларак файдаланылучы үсемлекләр чәчелгән кырлар булдыру.

3. Аучылык биләмәләрен сугару, аучылык ресурсларын саклау һәм аларны табигый яңарту өчен шартларны яхшырту, алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

үсемлекләр утырту;

аучылык ресурсларына ясалма үрчү, яшәү, саклану урыннары булдыру;

ясалма сулыклар төзү.

4. Аучылык ресурсларын күчерү, ул түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

аучылык ресурсларының яңа климатка яраклашуы һәм яңадан үз халәтенә кайтуы;

аучылык ресурсларын күчерү;

ярымирекле шартларда һәм ясалма яшәү тирәлегендә үстерелгән аучылык ресурсларын табигый яшәү тирәлекләренә күчерү.

Билгеләнгән аучылык җир-суларында биотехник чараларны үткәрү календарь ел дәвамында, аучылык хуҗалыгы килешүләрен төзегән юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан билгеләнә торган күләмдә һәм составта башкарылырга тиеш.

Проектлана торган биотехник чараларның исемлеге һәм күләме хуҗалыкның нинди юнәлештә эшләвенә, матди мөмкинлекләренә һәм интенсивлашу дәрәҗәсенә бәйле. Бары тик югары дәрәҗәдә оештырылган, ресурслардан төп файдаланучылар булып торучы аучылык хуҗалыкларында гына аучылык җирләрен һәм аның сыйфатын тамырдан үзгәртүне: урманнарны оешкан төстә кисү, аучылык хуҗалыгында аеруча кыйммәтле агачлар һәм куаклар төрләрен зур мәйданда үстерү, территорияне киптерү яки су белән уратып алуны проектларга мөмкин.

Татарстан Республикасы өчен биотехник чараларның нормативлары поши, кабан дуңгызы, ак куян һәм соры куян, урман киекләре һәм киек су кошлары өчен эшләнгән. Татарстан Республикасының климат үзенчәлекләрен исәпкә алып һәм биотехник чараларга булган чыгымнарны киметү максатларында, конкрет елда хайваннарны ашату вакытларын билгеләргә кирәк. Куян өчен бу чама белән 100 көн тәшкил итә, кыр кәҗәсе өчен – 90 көн (ноябрь азагыннан март аена кадәр), кабан

дуңгызы өчен – 180 көн. Минераль ризык ихтыяҗының яки аның җитәрлек булмавының күп очракта карала торган төбәктә сезонлы үзенчәлекләренә бәйле булмыйча, ә аның принципиаль рәвештә җитәрлек булуыннан чыгып ачыкланганлыгын исәпкә алып, тозлыкларның ел әйләнәсендә булуы зарур.

Аучылык ресурсларының биотехник чаралар үткәргәндә исәпкә алынырга тиешле кайбер үзенчәлекләрен билгеләп үтәргә кирәк.

Биотехник чаралар әлеге төр өчен бары тик уртача, яхшы һәм югары сыйфатлы булган яшәү урыннарында гына үткәрелергә тиеш (югары бонитетлы ау җирләрендә); начар сыйфатлы аучылык җирләрендә биотехник чаралар үткәрү нәтиҗә бирмәячәк.

Биотехник чараларны үткәргәндә аучылык ресурсларын сакларга кирәк (мисал өчен, язын атып үтерелгән ана кошның потенциаль үрчемен биотехник чаралар тулыландыра алмый).

Биотехник чараларны үткәргәндә аерым хайван төрләре өчен кайбер үзенчәлекләрне исәпкә алырга кирәк.

Пошu.

Поши өчен өстәмә тукландыру һәм минераль азык төп биотехник чара булып тора. Пошига азык итеп усакның, талның һәм башка агачларның кайрысы һәм үрентеләре файдаланыла, чөнки пошилар салам һәм силосны теләр-теләмәс кенә ашый. Әлеге максатларда урманнарда агач кисүдән калган калдыклар: усак ботаклары, шул ук токымдагы колгалар, яфраклы агачларның чыбык-чабыклары файдаланырга мөмкин, аларны пошилар кыш буенча яши торган урыннарда өем-өем итеп куялар. Кышкы чорда пошиларны ашату өчен барыннан да бигрәк урманны чистарту һәм сайлап алып киселә торган усаклар файдаланыла. Октябрь ахыры-ноябрь башыннан һәм март айларында усакны һәм талны 6–8 данә ясап кисү пошилар өчен яхшы азык булып тора. Пошилар өчен аеруча 35–45 яшьлек усакларны кисү максатка ярашлы булып тора. Бу очракта бер агач әлеге хайваннар ашау өчен яраклы 20–40 кг азык бирә ала. Ашату урыннары 1000 га мәйданда 1 ашату урыны исәбеннән урнаштырылырга тиеш, 1 мәйданчыкка уртача 5 усак кирәк.

Пошины минераль азык белән тукландыру тозлыклар урнаштыру юлы белән башкарыла, аларга ташлы тоз кисәкләре яисә йорт хайваннарын ашату өчен кулланыла торган тоз куела. Кагыйдә буларак, тозлыкларны тукландыру урыннары янәшәсендә, ягъни аударылган усаклар янында урнаштыралар. Пошилар тәүлегенә 30 г тоз ашарга тиеш, һәр тозлыкка елына 20-30 кило тоз китә. Аучылык биләмәләренең 1000 га мәйданда норма буенча 1 тозлык урнаштырыла, аучылык ресурсларын саклау зоналарында, яңартылган кишәрлекләрендә һәм заказникларда – 1000 гектарга 2 тозлык куела. Пошиларны минераль тукландыру аеруча декабрьдән башлап июнь аен да кертеп гамәлгә ашырылырга тиеш. Тукландыру урыннарын урман авызларында, болыннарда һәм урманның хайваннар еш туплана торган урыннарында урнаштырырга кирәк.

Кыр кәҗәсе.

Гамәлдә булган нормативлар буенча 1 кыр кәҗәсе бер сезонда 125 кило печән, 100 данә себерке, 88 кило сусыл һәм 24 кило концентратлы азык һәм шулай ук 5 кило тоз ашарга тиеш, дип билгеләнә. Моннан тыш 10 баш кыр кәҗәсенә бер сезон өчен 8 данәләп усак кисү киңәш ителә. Татарстан Республикасы өчен өстәмә тукландыруның дәвамлылыгы 90 көн дип билгеләнгән, ә ашату корылмалары саны – бер сезонда 10 баш өчен 2 тозлык һәм 2 шәр ашату урыны булырга тиеш.

Югарыда билгеләп үтелгән нормативларга төзәтмәләр кертү таләп ителә. Гамәли белгечләрнең күбесе кыр кәҗәләренең печән белән себеркене ашамавын билгели. Кыр кәҗәсен өйрәнү буенча әйдәүче белгеч А.А. Данилкин (1999) үзенең күзәтүләреннән һәм башка авторларның тикшеренүләреннән чыгып, аларга печән ашату зыянлы, хәтта хайваннарның үлеменә китерә дигән нәтиҗәгә килгән. Кыр кәҗәләре коры ризык ашаган вакытта су эчүгә мохтаҗ. Су җитмәгән очракта, кыр кәҗәләре кар ашарга мәҗбүр була, азыкта су азрак булган саен карны күбрәк ашый. Ләкин карда тозлар юк диярлек һәм аны эретү өчен бик күп көч куярга туры килә. Шуңа күрә нормаль шартларда һәм табигый сусыл ризык күп булганда, кыр кәҗәләре карны да, дымлылыгы нибары 12–22 % кына булган коры ризыкларны да ашамый диярлек.

Кышын, бигрәк тә салкын көннәрдә алар күбрәк мәңге яшел куаклыклар һәм ылыс ашый. Тәҗрибә барышында хайваннарның хәтта туклыклы матдәләргә бай ризык күп булган очракта да, ылыс ашавы ачыкланды. Ылыс алар өчен барыннан да бигрәк су һәм витамин чыганагы булып тора. Кыр кәҗәләренә коры ризык ашатканда һәм хәтта су булган очракта да алар ай саен тән авырлыгының 9,4 % массасын югалта. Аларның рационындагы печән сәламәтлеккә зыян китермичә, табигый ризыкларның бары тик 1,3 % ын гына биләп торырга тиеш.

Кышкы азык җитмәгәндә хайваннар коры ризык салынган җимлекләр һәм печән кучләре янында туплана. Хайваннар тора-бара хәлсезләнә һәм кыш ахырында яисә яз башында алар печәнле җимлекләр янәшәсендә һәлак була, кыр кәҗәләренең мондый үлеме чагыштырмача тотрыклы һәм дымлы Эстония климатында да билгеләнгән.

Югарыда билгеләп үтелгән барлык шартлар кыр кәҗәләре өчен мәҗбүри биотехник чараларга печән һәм себерке азыгы кертүне рөхсәт итми. Кыр кәҗәләре, пошилардан аермалы буларак, агачларның кайрысын ашамый, ә бары тик очларындагы үрентеләрен генә тешләп ала, шуңа да усак агачларын аударуның да максатка ярашлы булмавы мөмкин. Шуңа күрә кыр кәҗәләре өчен дип махсус рәвештә усак агачларын кисү максатка ярашлы түгел. Шул рәвешле, кыр кәҗәләре өчен мәҗбүри азык булып сусыл һәм туклыклы азыклар, шулай ук тозлыклар һәм тукландыру урыннары санала. Шул ук вакытта тукландыру урыннары сыйфатында хайваннарның бөртеклеләр утыртылган кырларны гына түгел, ә соңрак печән чабылган һәм кырпылар барлыкка килгән аланнарны да үз итүе билгеләнде. 1 кыр кәҗәсе өчен өстәмә тукландыру нормативлары 93 нче таблицада китерелгән.

93 нче таблица

Кыр кәҗәсе өчен өстәмә тукландыру нормалары

| Чараларның исеме | Үлчәү берәмлеге | Нормасы |
|---|---|---|
| Ашату дәвамлылыгы | тәүлек буе | 90 |
| 10 баш өчен ашату урыннары | данә | 2 |
| 10 баш өчен тозлыклар | данә | 2 |
| Өстәмә тукландыру (тәүлегенә 1 башка): 30 ноябрьгә кадәр 1 нче чор | | |
| туклыклы азык (ашлык) | кг | 0,03 |
| сусыл ризыклар (силос) | кг | 0,3 |
| 1 декабрьдән алып 31 декабрьгә кадәр (31 көн) 2 нче чор | | |
| туклыклы ризыклар (ашлык) | кг | 0,05 |
| сусыл ризыклар (силос) | кг | 0,05 |
| 1 гыйнвардан алып 3 нче чор | | |
| туклыклы ризыклар (ашлык) | кг | 0,08 |
| сусыл ризыклар (силос) | кг | 0,1 |
| Сезонда 1 баш санына тотылган азык күләме | | |
| туклыклы ризыклар (ашлык) | ц | 0,06 |
| сусыл ризыклар (силос) | ц | 0,07 |

Сусыл ризык буларак тамыразыклардан (азык чөгендере һәм шикәр чөгендере, кишер, шалкан, җир грушасы) кала силосны файдаланырга. Силосны һава температурасы 5˚С да түбән булмаганда салырга кирәк. Кыр кәҗәләре өчен елына бер тозлыкка 20 кило тирәсе тоз китә. Кыр кәҗәләре өчен яшәү урыны булып торган 1000 га аучылык биләмәләрендә тозлык куелган бер җимлек яисә 10–15 башка бер җимлек урнаштырыла. Кайбер очракларда кыр кәҗәләре азыкны җимлектән түгел, ә куакларга эленгән килеш ашарга өстенлек бирә. Өстәмә тукландыру вакыты кар катламының күпме вакыт саклануыннан чыгып билгеләнә һәм уртача 90 көн тәшкил итә. Азык салу өчен комплекслы ашату мәйданчыклары ясарга кирәк, аларда ашлык салу өчен тагарак, шулай ук тоз салу өчен улак куярга кирәк.

Кабан дуңгызы.

Татарстан Республикасында кабан дуңгызларын өстәмә тукландыру чорының дәвамлылыгы 180 көн. Азык буларак файдаланылучы үлән кырлары һәм ашату мәйданнары куе куаклыклар һәм вак агачлары күп булган биләмәләрдә урнаштырыла. Туклану урыннары янәшәсендә эктопаразитларны юк итә торган

креазот һәм башка төрле препаратлар салынган коену урыннарын булдыру зарур. Кабан дуңгызының бер баш санын өстәмә тукландыру өчен кирәкле биотехник чараларның нормативлары 94 нче таблицада күрсәтелгән.

94 нче таблица

Татарстан Республикасында кабан дуңгызы өчен кирәкле биотехник чаралар нормативлары

| Чараларның исеме | Үлчәү берәмлеге | Нормасы |
|---|---|---|
| Ашату дәвамлылыгы | тәүлек буе | 180 |
| 10 башны өстәмә тукландыру урыннары | данә | 1 |
| 10 башка исәпләнгән үлән кырлары саны | га | 0,5 |
| Ашату (1 башка тәүлегенә): 1 нче чор – 15 октябрьдән 30 ноябрьгә кадәр | | |
| Катнаш мал азыгы | кг | 0,4 |
| Туклыклы азык (ашлык) | кг | 0,3 |
| Тамыразыклар | кг | 0,6 |
| 2 нче чор – 1 декабрьдән 15 гыйнварга кадәр | | |
| Катнаш мал азыгы | кг | 0,8 |
| Туклыклы азык (ашлык) | кг | 0,6 |
| Тамыразыклар | кг | 1,2 |
| 3 нче чор – 16 гыйнвардан 15 апрельгә кадәр | | |
| Катнаш мал азыгы | кг | 1,3 |
| Туклыклы азык (ашлык) | кг | 1 |
| Тамыразыклар | кг | 2,4 |
| Сезонда 1 баш санына тотылган азык күләме | | |
| туклыклы ризыклар (ашлык) | ц | 0,06 |
| сусыл ризыклар (силос) | ц | 0,07 |

Тояклы кыргый хайваннар өчен люцерна, рапс, җир грушасы, көнчыгыш кәҗә үләне, кандала үләне, азык үлән (эспарцет), кытай борчагы, кәбестә, чөгендер, борчак, кәрешкә, солы, уҗым арышы һ.б. иң яхшы азык культуралары булып тора. Кәбестә һәм рапс дымны бик күп сеңдерә, шуңа алар көзен һәм кыш башында да яшел булып кала. Аларны гадәти агротехника срокларында чәчәргә һәм утыртырга кирәк.

Азыклар ачык һавада өем-өем череп ятарга тиеш түгел. Ашлыкны өсте ябулы яисә махсус ашлык саклау урыннарда сакларга кирәк.

Тоташ ашлыкны җимлеккә салыр алдыннан вакларга кирәк. Тәҗрибәдән күренгәнчә, бу очракта кабан дуңгызы ашлыкны өчтән бер өлешкә диярлек яхшырак эшкәртә. Шунысын билгеләп узарга кирәк, кыргый кабан дуңгызлары яңа төр ризыкка сак карый, хәтта ач булсалар да, аны шундук ашарга керешми. Кайчак алар атналар буе ризыкка кагылмый, җир грушасы плантацияләрен, бу төр азыкны ошатып ашаучы ач кабан дуңгызы очрамаса, ел буе да читләтеп узарга мөмкин. Тора-бара хайваннарның күбесе тамыр сайлау максатларында кырларга чыга башлый. Кайбер аучылык биләмәләрендә хайваннар, әгәр анда кәрешкә орлыклары күп булса, бөртекләргә тими. Кишер, кәбестә һәм турнепсны бөтен килеш аз ашый, әгәр вакласаң – күбрәк.

Күп кенә уку әсбапларында ауны оештыручылар һәм аучылык белгечләре өчен үсемлек азыгын тамырда килеш калдыру тәкъдим ителә. Ләкин тикшеренүләрдән күренгәнчә, бу очракта тояклылар биомассаның 1 дән алып 20 % ка кадәр өлешен генә куллана, ә җыеп алынган һәм кучләргә, эскертләргә, өсте ябулы урыннарга өелгән азыкны алар кышын 70–100 % кадәр ашап бетерә. Тамыр килеш үсемлекләрне чәчү мәйданына карап, иң күбе 1–10 % ын гына калдырырга кирәк. Югыйсә, кышкы азык кырдагы тычкансыман кимерүчеләр өчен генә яраклы булачак.

Соры куян, ак куян.

Куяннарны өстәмә тукландыру өчен ауган усак кайрылары һәм ботаклары, төрле агач һәм куакларның үрентеләре, куак ботаклары арасына куелган солы көлтәләре кулланыла. Куян аулау буенча махсуслаштырылган хуҗалыкларда үлән чәчелгән кырларны азык буларак файдаланырга киңәш ителә. Агачлар киселгән урыннарда киселгән агач ботакларыннан кучләр ясарга кирәк. Урман массивында өстәмә тукландыру урыннарын зур булмаган үзәннәрдә турыдан-туры чыршы агачлары янында урнаштырырга кирәк. Усакларны тозлыклар урнаштырган урыннарда кисәргә кирәк, чөнки мондый биотехник чаралар комплексы куяннарны сакларга һәм аларның санын арттырырга ярдәм итә. Усаклар бер җирдә 5–10 данә аударыла. Карт (30–40 еллык) усакларның шома яшел кайрылы ботакларын һәм кәүсәләрен куяннар, яшь агачларга караганда, яратыбрак ашый. Татарстан Республикасы шартларында соры куян яшәү тирәлеге булып торучы аучылык биләмәләрендә 1000 гектарга 5 ашату мәйданчыгы ясарга киңәш ителә, ак куян өчен – 3. Механизмнарны куллану мөмкинлеген исәпкә алып, ашату кырларының күләме кимендә 0,1–0,2 гектар булырга тиеш, алар ау биләмәләрендә тигез, юллардан һәм торак пунктларыннан еракта урнаштырыла. Куяннар өчен өстәмә тукландыру азыгының составы 95 нчы таблицада күрсәтелгән.

95 нче таблица

Татарстан Республикасында соры куян һәм ак куян өчен биотехник чаралар нормативы

| Чараларның исеме | Үлчәү берәмлеге | Нормасы |
|---|---|---|
| 1000 гектарда агачлар кисү | данә | 6 |
| 1000 гектарда азык кырлары | данә | 1 |
| яфраклы агачлардан ясалган себеркеләр | данә | 5 |
| ялый торган тоз | кг | 3 |
| тозлыклар | данә | 1 |
| Бу төргә хас булган 1000 га аучылык биләмәләрендә ашату мәйданчыклары (соры куян/ак куян) | данә | 5/3 |
| Өстәмә тукландыру азыгының составы: (10 башка; бер сезонда) соры куян өчен: Тамыразыклар | кг | 15 |
| | кг | 7,5 |

| Чараларның исеме | Үлчәү берәмлеге | Нормасы |
|---|---|---|
| печән (тукранбаш, люцерна, кәрешкә-солы катнашмасы)<br><br>солы (бөртек, бөртек калдыклары) | кг | 2 |

Татарстан Республикасында куяннарны өстәмә тукландыру вакыты – якынча 100 көн. Табигый тозлыкларга кытлык булган районнарда куяннарны аш тозы белән тәэмин итәләр. Татарстан Республикасында 1000 га җирдә 2 тозлык урнаштырырга, ә аучылык ресурсларын саклау зоналарында, яңарту кишәрлекләрендә һәм заказникларда тозлыклар санын 1000 гектарга 4 данәгә кадәр арттырырга кирәк. Куяннар тәүлегенә уртача – 2 г, ә елына 0,4 кг тоз ашарга тиеш. Тозлыкларның күләменә һәм куяннар санына карап, елына бер тозлыкка 3–5 кг тоз китә. Куяннар өчен тозлыклар урман авызларында, болыннарда, урман ызаннарында, агач ташый торган ташландык юл кырыйларында, кояш яхшы җылыта торган, хайваннар еш килә торган барлык урыннарда (аларның сукмаклары күп булган җирләрдә) урнаштырыла. Иң беренче чиратта тозлыкларны куяннар иң күп булган урыннарда куярга кирәк. Кырлар янәшәсендә, яшь урман буйларында, болыннарда һәм кыр арты чикләрендә дә тозлыкларны кую зарур. Ашату урыннарын һәм тозлыкларны коры, сазлыклы булмаган карт урман кишәрлекләрендә урнаштырырга кирәк – бу инвазион чирләр таратуны бетерә.

Киек су кошлары.

Киек су кошларының санын арттыру өчен иң төп биотехник чаралар аучылык җирләрендә ясалма оя урыннары корудан гыйбарәт. Оялар кору өчен урыннар җитәрлек булмау аларның таралуына начар йогынты ясаучы иң әһәмиятле фактор булып тора, нәтиҗәдә аучылык биләмәләрендә киек су кошлары өчен ясалма оялар аларның санын берничә тапкырга арттырырга ярдәм итә.

Елга үрдәкләре өчен ясалма оялар үрдәкләр салган күкәйләрне коры җир ерткычларыннан һәм каурыйлы ерткычлардан, начар һава шартларыннан сакларлык итеп һәм шулай ук аучылык биләмәләрендә оя коручы кошларның яшәү тыгызлыгын арттырырлык итеп урнаштырыла. Яр буе үсемлекләрендә, утрауларда һәм су үсемлекләрдә төрле оялар урнаштырыла: каерылган куаклыкларда оялар, куышлар ясап, тактадан җир асты корылмалары, агач йортлар, сыерчык оялары, ясалма оялар. Татарстан Республикасы шартларында үрдәкләр яшәү тирәлеге булып торучы җирләрдә 1 гектарга 20 тирәсе ясалма оя ясарга киңәш ителә.

Урман киекләре.

Урман киеген ашату өчен вакланмаган солы, тары һәм карабодай көлтәләре кулланыла, аларны колгаларга яки агачларга эләләр. Бөртекле азыкны төрле җимлекләргә салалар, анда шулай ук төрле җиләк-җимеш, мәсәлән, миләш салырга киңәш ителә. Тавыксыман кошларның барысы да көзге-кышкы чорда чуерташ яки эре бөртекле ком (гастролит) кебек минераль кисәкчекләргә мохтаҗ, алар кошларның ашказанында каты азыкны ваклау өчен кирәк. Шулай ук туфракта коенып, паразитлардан арыну урыннары (туфрак оемнәре) булдыру да кошлар өчен

зур әһәмияткә ия. Шуңа күрә тавыксыман кошларның тереклегенә ярдәм итүдә көзге-кышкы чорда чуерташ оемнәре ясау әһәмиятле чара булып тора. Татарстан Республикасында урман киеге яши торган аучылык биләмәләренең 8000 гектары саен 1 чуерташ өеме һәм охшаш биләмәләрнең 1000 гектары саен 5 туфрак өеме корырга киңәш ителә. Кошлар өчен чуерташлыкларны эре комлы зур күлләр рәвешендә ясыйлар яисә зур булмаган бураларга (1–2 рәт бүрәнә) ком салалар. Һәр бурага 1 кубометрга якын ком, вак таш салына. Алар җимлекләр һәм туфрак оемнәре белән комплекста ясала. Кошларны юлга якын җибәрмәү өчен чуерташлыкларны юл буйларында 300-500 метр аша юл өслегеннән урманга таба 150–300 метр ераклыкта урнаштырырга кирәк. Кышкы чорда чуерташлыкларны кардан чистартып тору яки аларның өстенә түбә кору максатка ярашлы була.

Суер.

6–8 метр озынлыктагы, 1,5–2 киңлектәге, 2,5 метр биеклектәге ике ярусл стационар җимлекләр кыр тавыгы өчен иң яхшысы булып санала. Өске платформа түбә ролен үти һәм аскысын явым-төшемнәрдән саклый. Аскы өлештә азык (бөртек, җиләк-җимеш), гравий, ком салынган яссы әрҗәләр урнаштырыла. Азык 1 кошка тәүлегенә 30 г бөртек исәбеннән салына.

Көртлек.

Бөртекле (солы, карабодай, тары) көлтәләрне берничәшәр (4–6 данә) итеп кую яки агачларга яисә махсус ясалган элгечләргә ашату урыннарында элү көртлекләрне ашату өчен иң яхшы ысул булып санала. Азыкка миләш өстәгәндә, аны киптерелгән килеш кулланган яхшы. Чуерташлыклар һәм туфрак оемнәре кору файдалы, аларны ашату урыннары белән бергә комплекслап урнаштыралар. Азык 1 кошка тәүлегенә 20 г бөртек исәбеннән салына.

Аучылык ресурсларының һәлак булуын кисәтү.

Аучылык ресурсларының һәлак булуын кисәтү буенча төп чаралар – аучылык ресурсларын саклау (законсыз аулауны бетерү), житештерү процессларында аучылык ресурслары һәлак булуны туктату.

Аучылык ресурсларын саклау биотехник чараларның төп төре булып санала, чөнки сакламаганда, биотехник чараларның башка төрләре нәтиҗәсез.

Ау хайваннарын саклау чаралары берничә юнәлеш буенча оештырылырга тиеш:

җәмәгатьчелектә хайваннар дөньясын саклауны пропагандалау, ау кагыйдәләрен массакүләм мәгълүмат чаралары ярдәмендә үтәү буенча системалы эш алып бару. Ау кагыйдәләрен үтәү һәм кыргый хайваннарны саклау буенча әлеге чаралар ай саен, шулай ук язгы, җәйге-көзге ауны һәм тояклыларга ау ачу алдыннан планлаштырыла. Аңлату һәм пропаганда эшен үткәрү өчен ау буенча белгеч җаваплы;

квалификацияле аучылар составын һәм иң актив аучылар арасыннан җәмәгатьчелектә эш алып баручы аучыларны әзерләү буенча программалар төзү һәм гамәлгә ашыру. Укытуның максаты – аучыларда ныклы оператив эш күнекмәләрен булдыру.

Икенче юнәлешне гамәлгә ашырганда, аучылык җирләренә патрульлек итү башкарыла. Мондый урынга чыгып күзәтүләр актив һәм пассив ысуллар белән башкарылырга мөмкин.

Актив патрульлек итү – иң нәтиҗәле ысул, аның уздырганда хәрәкәтнең юнәлеше аучыларның мылтык тавышлары, эзләре, гөлдердәү, киекләрнең туплану урыннарына, тозлыкларга, ашату мәйданчыкларына һәм азык кырларына карап, шулай ук тавышлар, эт өрүләр, аучылык җирләрендә калдырылган транспорт чаралары һәм аларның эзләре буенча билгеләнә.

Пассив патрульлек итү – сак чаралары аучылар иң еш килә торган урыннарда урнашкан күзәтү пунктыннан оештырыла торган ысул.

Ау хайваннарының җитештерү процесслары вакытында һәлак булуы, алар үлеменең җитди факторы булып тора. Тикшеренүләр барышында барча механикалаштырылган кыр эшләре вакытында авыл хуҗалыгы машиналары көпчәге астында кыргый җәнлек-җанварларның һәлак булы ачыкланды. Иң күп югалтулар киекләрнең соры куян һәм соры урман тавыгы кебек төрләре популяциясендә күзәтелә. Шулай ук яшь кыр кәҗәләренең, урман фаунасы вәкилләренең (ак куян, көртлек) һәлак булуы да еш очрый. Һәлак булган киекләр саны аучылар аткан белән чагыштырганда, берничә мәртәбә артып китүе билгеле. Югарыда бәян ителгәннәрне һәм төбәктә авыл хуҗалыгының югары үсешен исәпкә алып, Татарстан Республикасының аучылык хуҗалыклары өчен җитештерү процессларында аучылык ресурсларының һәлак булуын туктатуның бик актуаль булуын билгеләргә кирәк. Моның өчен авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә аңлату эшләре алып барырга, авыл хуҗалыгы культураларын җыеп алуның кагыйдәләре үтәлешен, агулы химикатлардан һәм минераль ашламалардан файдалану кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тотуны җайга салырга кирәк. Кырдагы механикалаштырылган эшләр вакытында кыргый җәнлек-җанварларның һәлак булуын киметү өчен үлән чабу, бөртекле һәм башка авыл хуҗалыгы культураларын җыю эшләрен урман авызына, урманлыкка, башка авыл хуҗалыгы культурасы үсеп утыручы кишәрлеккә терәлеп торган якка каршы яктан башлап җибәрергә, киекләргә чабылачак культура арасыннан куркынычсызрак җиргә качу өчен мөмкинлек тудырырга кирәк. Үләннәрне машиналар белән чабуны урау ысулы белән башкармаска кирәк, чөнки кыр читеннән уртага таба барганда, киекләр уртарак бер җирдә тупланып, ахыр чиктә көпчәк астында кала. Киресенчә «куып тарату» ысулы белән чапканда, киекләр чабылачак үсемлекләргә ышыкланып янәшәдәге кишәрлекләргә кача. Урып-җыю эшләре вакытында техника кырның урта бер җиреннән эшли башларга тиеш. Моннан тыш, урып-җыю техникасын куркыткыч җайланмалар (механик, ут ярдәмендә) белән җиһазлау да җәнлек-җанварларның үлемен кисәтүдә уңай нәтиҗә бирә.

### 7.2. Акклиматизация эшләрен үткәрү чаралары

Акклиматизация – ят яңа төрләрне җирле фаунага һәм табигый экосистемаларга җибәрү дигәнне аңлата.

Татарстан Республикасы территориясендә акклиматизация эшләре алып барылмый һәм планлаштырылмый да. Территорияләргә җайлаштыру өчен яңа төр

җәнлек-җанварларны һәм кошларны ireккә җибәрү бары тик түбәндәге очракларда гына максатка ярашлы:

хуҗалык биләмәләре әлеге төрләргә тереклек итәр өчен яраклы (биләмәләр кимендә III бонитет дәрәҗәсендә) булса;

биләмәләргә җибәрү планлаштырылган төрләрнең саны кимүгә сизелерлек йогынты ясардай ерткычлар һәм бу төрләрнең конкурентлары булмаган яки аз булган җирләрдә;

иреккә җибәрелә торган яңа төр җирлектәге перспективалы төрләргә конкурент булмаса;

иреккә җибәрү күз алдында тотылган төрнең баш саны оптималь күрсәткечтән узып китеп, хуҗалыкның башка тармакларына зыян китермәсә;

җәнлек-җанварлар партиясен иреккә җибәрү, ә кирәк чакта, аларны карап тоту, ашату, саклау һәм башка максатлар өчен кирәкле акча хуҗалыкта җитәрлек булса.

Җирле фауна төрләрен биләмәләргә чыгару бары тик түбәндәге очракларда гына максатка ярашлы:

төрнең юкка чыгуы яки аның саны кисәк кимү тереклек итү шартларына бәйле булмыйча, ә ниндидер вакытлыча факторлар: кирәгеннән артык аулау, эпизоотия яки сирәк була торган начар климат шартлары аркасында барлыкка килсә;

җәнлек-җанварлар саны оптималь дәрәҗәдән артып китеп, алга таба аларны ату өчен.

Әгәр җирле төрләрнең саны тереклек итү шартлары начараюга (биләмәләрне кеше үзгәртү нәтиҗәсендә) бәйле кисәк кимесә, биләмәләрнең торышын яхшырту һәм шуңа юнәлдерелгән биотехник чаралар комплексын үткәргәндә генә төрләрне иреккә җибәрү максатка ярашлы була.

Җәнлек-җанварларны читтән кертекәндә һәм ирeккә чыгарганда түбәндәге таләпләрне үтәргә кирәк:

ирeккә җибәрелә торган хайваннар җибәрелә торган район шартларына охшаш биләмәләрдән китертелергә тиеш;

ирeккә җибәрүне зур-зур партияләр белән башкарырга кирәк;

транспортта китергәннән соң җәнлек-җанварлар ирeккә җибәргән җирдә тоткарлана;

зәгыйфь һәм авыру җәнлек-җанварларны ирeккә чыгармыйлар, бәлки терелгәнче вольерларда калдыралар яки бракка чыгаралар;

ирeккә җибәрүне үрчү сезоны алдыннан үткәрергә кирәк, кагыйдә буларак, кар тирән һәм азык аз булу сәбәпле яз башында җәнлек-җанварлар һәм кошлар ирeккә җибәрү урыныннан ерак китмиләр, әлеге шартларда алар чыгару урыннарында тоткарланырга һәм даими рәвештә ашату урыннарына барырга мәҗбүр була.

Ирeккә җибәргәннән соң җәнлек-җанварларны даими күзәтеп торырга, күпләп ашатырга, ерткычларны интенсив рәвештә атып торырга кирәк.

### 7.3. Татарстан Республикасында аучылык ресурсларын авырулардан саклау буенча ветеринария-профилактика чаралары һәм эпизоотиягә каршы чаралар, аларны аучылык биләмәләрендә үткәрү буенча киңәшләр

Аучылык биләмәләре территорияләрендә килеп чыгуы мөмкин булган эпизоотия күренешләреннән аучылык ресурсларын саклау өчен ветеринария һәм зоотехника эшчәнлеге алып бару мөһим. Әлеге өлкәне җайга салу хәзерге вакытта «Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге ФЗ-52 номерлы Федераль закон, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законы. Күрсәтелгән документларда әлеге эшчәнлекне алып баруны җайга сала торган норматив документларны, кагыйдәләрне, инструкцияләрне һәм башка норматив актларны үтәү өчен җаваплылык каралган.

Ветеринария-профилактика чаралары һәм эпизоотиягә каршы чараларга йогышлы авырулы киекне исәпкә алу һәм тоту, ветеринария препаратларыннан файдалану, шул исәптән аларны киекләрнең азыгына кушып бирү юлы белән дә, һәм шулай ук исемлеген вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы раслый торган башка чаралар керә.

Беркетелгән аучылык биләмәләрендә аучылык ресурсларын авырулардан саклау чараларын үткәрү ау хуҗалыгы белән килешү төзегән юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан гамәлгә ашырыла. Аучылык хуҗалыгы килешүләре нигезендә, аучылык ресурсларын авырулардан саклау буенча ветеринария-профилактика чаралары һәм эпизоотиягә каршы чаралар исемлеге расланды. Мондый чараларга түбәндәгеләр керә:

чир йоктыручы җәнлек-җанварларның читтән керүен кисәтү һәм аучылык биләмәләре территорияләрендә аларга таралырга ирек куймау;

җәнлек-җанварлар үләксәсе табылганда, бу турыда мәҗбүри хәбәр итү;

йогышлы авырулы киекләрне аерып алу, аучылык ресурслары авырулары барлыкка килүне һәм таралуны туктату максатында аучылык ресурслары санын көйләү чараларын оештыру;

киекләрнең авыруларын кисәтү һәм дәвалау өчен ветеринария препаратларын куллану, карантин барышында үткәрелгән диагностика тикшеренүләре нәтиҗәләре буенча тиешле эшкәртүләрне, иммунопрофилактиканы башкару, аучылык биләмәләре территориясенә йогышлы чир белән авыручы җәнлек-җанварларны кертмәү һәм аларның таралашын булдырмау өчен киекләрне бракка чыгару.

Төрле авырулар ау хайваннарының һәм кошларының санына йогынты ясаучы фактор булып тора. Иң куркыныч дип себер түләмәсе, пастереллез, кокцидиоз, бруцеллез, туляремия, котыру чире, дерматозлар, гельминтозлар һәм башкалар санала.

Киекләргә чирне бактерия һәм вирус йөртүче, табигатьтә булган башка төрле чир таратучылар йоктыра. Аларның саны күп булганда, бигрәк тә авыр кыштан соң яз кергәч җәнлек-җанвар азык җитмәү сәбәпле зәгыйфьләнгән чакта, эпизоотия характеры алучы авырулар барлыкка килә. Шуңа күрә аучылык хуҗалыкларында ветеринария-профилактика чараларын уздыруга аеруча зур ихтыяж туа.

Аучылык биләмәләрендә үткәрелә торган чаралар өч төркемгә бүленә: йогышлы чир таралуны туктату өчен киекләрне йорт хайваннары белән элемтәгә

кертмәү, биләмәләрдәге гомуми санитария чаралары һәм махсус профилактика чаралары.

Беренче төркемгә түбәндәгеләр керә:

терлекләрне күзәтчесез көтүне тыю (киекләр аеруча күпләп тупланган урыннарда);

ужалыкка керү юлларында тиешле күләмдә дезинфекция киртәләре кору;

хуҗалык территориясендәге барлык йорт хайваннарын мәҗбүри вакцинацияләү;

хуҗалык территориясендәге этләрне теркәү һәм аларны елына кимендә ике тапкыр дегельминтизацияләү.

Гомуми санитария чараларына түбәндәгеләр керә:

түбәнлекләрдә урнашкан ашату мәйданнарын һәм тозлыкларны дренажлау;

ел саен ашату мәйданнарын, җимлекләрне, тозлыкларны чистарту һәм йогышсызландыру;

хайваннарга сыйфатлы азык бирү.

Махсус профилактика чараларына түбәндәгеләр керә:

хайваннарның санын оптималь дәрәҗәдә тоту;

барлык зәгыйфь, травма алган яки авыру хайваннарны ел дәвамында бракка чыгару;

азыкка һәм тозлыкларга кирәкле дару препаратларын өстәү.

Профилактика максатларында системалы рәвештә (ел дәвамында) зәгыйфь хайваннарны атарга (селекцион ату), һәм шулай ук территорияне даими чистартып торырга һәм киек үләксәләрен яндырырга киңәш ителә.

Аларның гемеостазын савыктыру һәм арттыру максатында популяцияләргә турыдан-туры йогынты ясауның башка чаралары да бар. Кагыйдә буларак, киекләрнең юкка чыга баруы түбәндәге очракларда чагыла:

азсанлы популяция нинди дә булса чикләүче факторлар йогынтысында изоляцияләнгәндә;

популяция бик каты сирәкләнгән очракта, бу бер оядан чыккан җәнлек-җанварларның пар коруы;

көтүнең оптималь структурасы бозылган очракта, бу хәл ата җәнлек-җанварларны күпләп атканда барлыкка килә, нәтиҗәдә ата җәнлек-җанварларның конкрет шартларда балалары күпләп бер урында туплана, алары соңыннан бер-берсе белән кирәгеннән артык еш пар кора.

Хәзерге вакытта ветеринария хезмәтенең рәсми мәгълүматларын анализлап, киекләрнең күпчелек авырулары буенча эпизоотиягә карата Татарстан Республикасы имин, ә котыру чире буенча иминлексез дигән нәтиҗә ясарга була. Әйтик, соңгы 5 елда хайваннарның котыру белән чирләве ешрак теркәлә башлаган. Шул ук вакытта республикада котыру чиренең төп чыганагы һәм таратучысы булып төлкеләр санала, авыру йоктырган киекләр арасында аларның өлеше – 80 %. Татарстанның икътисадый районнары буенча котыру чиренең таралышын анализлау нәтиҗәсендә республиканың Актаныш, Алексеевск, Биектау, Лаеш, Лениногорск районнарының һәм Казан шәһәренең иң иминлексез булуы ачыкланган.

Моннан тыш, тычкан бизгәге буенча киеренке эпидемиологик хәл кала. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк, Татарстан Республикасы буенча тулаем алганда тычкан

бизгәге авыруларының кимүе күзәтелә. 2020 елда республикада үлем очраклары теркәлмәгән. Тычкан бизгәгенең резервуары, нигездә, кыр тычканы һәм кимерәк дәрәҗәдә башка кимерүчеләр.

Шуннан чыгып, аучылык ресурсларын авырулардан саклау буенча шәхси киңәшләрне эшләгәндә, котыру һәм тычкан бизгәге белән көрәшү буенча чаралар үткәрүгә аеруча зур игътибар бирергә кирәк. Әйтик, котыру чирен таралуны туктату өчен түбәндәгеләр киңәш ителә:

мәчеләрнең һәм этләрнең хуҗалары аларны торак пунктларда тоту өчен билгеләнгән тәртипләр нигезендә тотарга тиеш;

аучылык хуҗалыклары җитәкчеләре үзләренең хезмәткәрләре һәм җирле аучылар өчен авыруның асылын һәм хайваннарны карап тоту кагыйдәләрен аңлату буенча семинарлар яки башка коллектив чаралар үткәрергә тиеш. Үлгән хайваннарның үләксәләрен очратканда яисә үзен сәер тотучы яисә тышкы кыяфәте авыру кыргый ерткыч хайваннарны тотканда, котыру чирен диагностикалау өчен аларны бөтен килеш ветеринария лабораториясенә тапшыру буенча агитацияләр үткәрергә. Ерткыч йорт хайваннарын вакцинацияләүне контрольдә тотарга һәм ясалган прививкалар турында паспорты булмаган (котыру чиреннән вакцинацияләнгән) яки бер ел элек прививка ясалган этләрне ауга якын китермәскә.

ветеринария хезмәтләре белән килештереп, ерткыч хайваннар иң күп йөри һәм аларның туплану урыннары булган җирләрдә антирабик вакцина таратуны оештырырга.

Тычкан бизгәге таралуны туктату максатларында, аучылык хуҗалыклары җитәкчеләре үзләренә беркетелгән биләмәләрдә шәһәр дезинфекция станцияләре, Госсанэпиднадзорның инфекция чыганакларын юк итү буенча шәһәр һәм район үзәкләренең профилактика дезинфекция бүлекләре белән берлектә чаралар үткәрергә тиеш, алар арасында түбәндәгеләр мәҗбүри булып санала:

торакларны, склад һәм җитештерү биналарын, кыр шартларында кешеләрнең вакытлыча яшәү урыннарын кимерүчеләрдән саклау. Урман янәшәсендә урнашкан торак пунктларда азык-төлек продуктларының кимерүчеләр үтеп керә алмый торган складларда саклануын, чүп-чарның төзек капкачлары булган әрҗәләргә салынуын кайгыртырга кирәк.

кимерүчеләрнең баш санын даими күзәтеп торырга, аларны күргән урыннарда һәм алар тупланырга мөмкин булган урыннарда дератизацияләү өчен препаратлар куярга. Торак йортлар, ишегалды корылмалары, каралтылар, 300 метрга якын урман полосалары эшкәртелергә тиеш. Кимерүчеләрне юк итү өчен цинк фосфиды (3 %) яки зоокумарин (10 %) белән катнаштырылган бодай бөртеге файдаланыла. Бодай яки оннан ясалган алдавычлар озак вакытка яхшы нәтиҗә бирә. Торак пунктларда, сәнәгать объектларында һ.б. җирләрдә массакүләм дератизация ясау аеруча яхшы нәтиҗә бирә. Шул ук вакытта үткәрелгән әлеге чаралар турында халыкка гомуми мәгълүмат җиткерү балалар һәм йорт хайваннарының агулануын киметәчәк;

торак йортлар янында урнашкан территорияләрне чисталыкта тотарга кирәк. Чүплек чокырларын торак биналардан 100–150 метр ераклыкта урнаштырырга киңәш ителә. Урманда урнашкан корылмалардан 100 метр ераклыктагы радиуста мәйданнарны чыбык-чабыктан арындырырга, чүп үләннәреннән һәм куаклыклардан

чистартырга кирәк. Бу көзге-кышкы чорда торак йортларда һәм эш урыннарында кимерүчеләр оялау өчен мөмкинлек калдырмый.

Хәзерге вакытта дуңгызлар арасында африка чумасы таралу куркынычы булу сәбәпле, түбәндәге киңәшләрне файдаланырга кирәк.

1. Ау оештыру буенча хезмәтләр күрсәтүгә шартнамә (юллама) төзегәндә аерым аучылык хуҗалыгында ауга чыгарга план коручы затлардан аларның элекрәк африка чумасы чыганаклары теркәлгән Россия Федерациясе субъектларында булу-булмавы турында белешергә.

2. Татарстан Республикасының аучылык хуҗалыкларында ауга чыгарга җыенган затлардан 1 пунктта күрсәтелгән мәгълүмат расланган очракта, ауны башлар алдыннан, элегрәк африка чумасы буенча иминлексез саналган аучылык хуҗалыклары территорияләрендә ау вакытында киеп йөргән аяк-киемнәрен, алар ярдәмендә кабан дуңгызларын эшкәрткән пычакларны чистартырга һәм дезинфекцияләргә, ау экипировкасы элементларын (өске кием, перчаткалар һ.б.) алмаштырырга киңәш ителә.

3. Африка чумасы буенча имин булган территорияләрдә ауга чыкканда элегрәк африка чумасы буенча иминлексез аучылык хуҗалыкларында табылган кабан дуңгызларын яисә аларның кисәкләрен алып барган авторанспорттан файдаланырга теләгән очракта, аучыларга яисә аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек баручы затларга транспортны һәм аның багаж бүлемтекләрен дезинфекцияләргә яки мондый автотранспортны аучылык хуҗалыгы территориясенә кертмәүне һәм аннан файдаланмауны тәэмин итәргә тиеш.

4. Аучыларга һәм/яки аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек башкаручы затларга ветеринарлар органнары белән берлектә ауланган кабан дуңгызларына ветеринария-санитария экспертизасы үткәрергә.

5. Ауланган кабан дуңгызларына ветеринария-санитария экспертизасы үткәрмичә, хайваннарауларга чыккан очракта аучылык ресурсларын ауларга рөхсәт кәгазен япмаска.

6. Аучыларга һәм/яки аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек башкаручы затларга ветеринария органнары белән килештереп, ауланган кабан дуңгызының эчке органнарын, тиресен һәм кешеләр ашамый торган башка өлешләрен күмү урыннарын табарга һәм аларны башка кыргый һәм йорт хайваннары таратмаслык итеп юк итәргә (яндырырга, кимендә 1,5 метр тирәнлектә күмәргә), шул ук вакытта күмү урыннарын африка чумасы вирусын бетерә торган чаралар файдаланып, мәҗбүри рәвештә дезинфекцияләргә кирәк.

7. Хайваннарны аучылык хуҗалыкларында идәннәрен һәм диварларын берничә тапкыр юарга һәм йогышсызландырырга мөмкин урыннарда үзәкләштерелгән рәвештә эшкәртергә кирәк. Ауланган кабан дуңгызы түшкәләрен эшкәртү урыннарын йогышсызландыру өчен техник чаралар сыйфатында җылы вакытта кимендә 5 литрлы букчасыман сиптерткечләрдән, кышкы чорда, инструкцияләреннән файдаланып, порошоксыман йогышсызландыру чараларыннан файдалану рөхсәт ителә. Түшкәләрне үзәкләштерелгән рәвештә эшкәртү өчен шартлар булмаганда, санап кителгән киңәшләрнең 5 һәм 6 пунктларында күрсәтелгән тәкъдимнәре үтәргә.

8. Ауланган хайваннарны ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларын һәм җайланмаларны йогышсызландырырга.

9. Ауланган кабан дуңгызы түшкәләрен үзәкләштерелгән эшкәртү урыннарына илткәндә хайваннарның каны яки табигый бүлендекләре җиргә яки транспорт чараларының төрле өслекләренә эләкмәсен өчен җайланмалардан (тиешле зурлыктагы пластик яки металл савытлардан) файдаланырга.

10. Кабан дуңгызын аулаганнан һәм аның түшкәсен эшкәрткәннән соң кулларны, аяк киемнәрен, шулай ук пычакларны, ыргакларны, балталарны, бауларны һәм башка җайланмаларны йогышсызландырырга.

11. Транспортка һәм киемнәргә кан, ит суты һ.б.дан зарарлы матдәләр күчмәсен өчен аучылык хуҗалыкларыннан ау продукциясен бары тик үткәрмәүчән савытта гына (полиэтилен һәм башка тиешле тыгызлыктагы материаллардан ясалган капчыкларда) күчерергә кирәк. Мөмкин булганда ау продуктларын күчерү өчен транспорт чараларының резина яки пластик тагараксыман келәмнәр түшәлгән багаж бүлемтекләреннән генә файдаланырга.

12. Аучыларга һәм (яки) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек алып баручы затларга полиэтилен һәм башка пакетларны (капчыкларны) азык салу өчен кабат кулланмаска, аларны әйләнә-тирәгә африка чумасы таралмаслык итеп юк итәргә.

13. Авыл җирлегендә яшәүче аучыларга һәм (яки) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек алып баручы затларга ауланган кабан дуңгызларының кулинар эшкәртү узмаган ите яки субпродуктлары юылган суны дуңгызларга һәм башка йорт хайваннарына эчертү өчен кулланмаска.

Мондый суны түгәр алдыннан биш минут кайнатырга яки химик чаралар белән йогышсызландырырга кирәк.

14. Аучылык биләмәләрен карап чыгу, саклау яки ау барышында кыргый дуңгызлар үләксәләре яисә үз-үзен тотышы аларның табигый рефлексларына туры килми торган хайваннар ачыкланганда һәм шулай ук әлеге билгеләре булган хайваннарны атканда, дәүләт ветеринария хезмәте органнарына (ветеринария табибына, участок ветеринария хастаханәсенә, хайваннар авырулары белән көрәшү станциясенә, Россельхознадзор территориаль органы), шулай ук башка хакимият органнарына хәбәр итәргә.

15. Африка чумасы буенча иминлексез аучылык хуҗалыкларында башка аучылык хайваннары төрләрен аулаучы, авыл җирлегендә яшәүче һәм хуҗалыкларында йорт дуңгызларын тотучы аучыларга һәм (яисә) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек алып баручы затларга аяк киемнәрен тәкъдимнәрнең 6 һәм 13 пунктларында күрсәтелгәнчә чистартырга (юарга) һәм йогышсызландырырга кирәк.

### 7.4. Аучылык ресурслары төп төрләренең максималь файдалану мөмкин булган һәм хуҗалык өчен максатка ярашлы баш саны күрсәткечләре

Аучылык ресурсларының популяцияләре белән идарә итү өчен һәм алардан рациональ файдалануны планлаштырганда яшәү тирәлегенең сыйфатнамәсенә бәйле рәвештә, хайваннарның төрле төрләренең максималь мөмкин булган һәм хуҗалык өчен максатка ярашлы (оптималь) баш саны турында мәгълүмат әһәмияткә ия.

Һәр бонитет классы өчен мәйдан берәмлегенә хайваннарның билгеле бер баш саны, ягъни азык ресурсларын нормаль җитештерүгә зыян китермичә, җирләрнең җитештерү үзенчәлекләре тулысынча кулланыла торган баш саны туры килә.

Аучылык белән шөгыльләнүчеләрнең бурычы – аучылык хайваннары баш санын якынча иң күп баш санына туры килүче хуҗалык өчен максатка ярашлы баш саны дәрәҗәсендә тотрыклылыгын саклау. Татарстан Республикасында исәп алып бару өчен нигез итеп төрле бонитет классларындагы яшәү өчен яраклы биләмәләрнең 1000 гектарына аучылык ресурсларының оптималь яшәү тыгызлыгы шкаласы файдаланыла (96 нчы таблица).

96 нчы таблица

Аучылык хайваннарының оптималь яшәү тыгызлыгын бәяләү шкаласы (баш саны/1000 га)

| Хайванның төре | Бонитет класслары | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | I | II | III | IV | V |
| Пош**и** | 10 һәм 13<br>артык | 10-6<br>8 | 6-4<br>5 | 4-2<br>3 | 2 һәм азрак<br>1 |
| Кабан дуңгызы | 15 һәм күбрәк<br>20 | 15-10<br>12 | 10-6<br>8 | 6-2<br>4 | 2 һәм азрак<br>1 |
| Кыр кәҗәсе | 60 һәм күбрәк<br>75 | 60-39<br>50 | 39-21<br>30 | 21-9<br>15 | 9 һәм азрак<br>5 |
| Ак куян | 120 һәм күбрәк<br>140 | 120-70<br>95 | 70-40<br>55 | 40-10<br>25 | 10 һәм азрак<br>5 |
| Соры куян | 60 һәм күбрәк<br>80 | 60-40<br>50 | 40-20<br>30 | 20-10<br>15 | 10 һәм азрак<br>5 |
| Суер | 100 һәм күбрәк<br>80 | 80-50<br>65 | 50-30<br>40 | 30-10<br>20 | 10 һәм азрак<br>5 |
| Көртлек | 200 һәм күбрәк<br>250 | 200-130<br>165 | 130-70<br>100 | 70-30<br>50 | 30 һәм азрак<br>15 |
| Соры кыр тавыгы | 300 һәм күбрәк<br>375 | 300-195<br>247 | 195-105<br>150 | 105-45<br>75 | 45 һәм азрак<br>22 |
| Су киек кошлары | 1000 нән артык | 1000-700 | 700-300 | 300-100 | 100 дән азрак |

Искәрмә: санаучыда – хайваннарның оптималь баш санының минималь һәм максималь мәгънәсе, ваклаучыда оптималь баш санының уртача күрсәткече китерелә.

Бонитет шкала мәгълүматларын кулланып, аучылык хайваннарының төп төрләре яшәү өчен яраклы мәйданнарны исәпкә алып һәм җирләрнең сыйфатын бәяләп, аларның хуҗалык өчен максатка ярашлы һәм максималь мөмкин булган баш санын исәпләп чыгарырга мөмкин. Аучылык хайваннарының максималь мөмкин булган баш санын исәпләгәндә хайваннарның оптималь баш санының максималь

мәгънәсе кулланылды (97 нче таблица); хуҗалык өчен максатка ярашлы баш санын исәпләгәндә, яшәү тирәлегенең барлык җирле үзенчәлекләрен исәпкә алып, шкала диапазоныннан чыгып уртача мәгънәләр кулланылды (98 нче таблица).

97 нче таблица

Татарстан Республикасында хайваннарның төп төрләренең максималь баш санын исәпләү

| Т/с | Аучылык ресурсларының төп төрләре | Яшәү тирәлеге мәйданы, га | Бонитет | 1000 га максималь баш саны | Татарстан Республиканың барлык территориясендә максималь баш саны |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Поши | 1366791,295 | IV | 4 | 5467 |
| 2 | Кыр кәҗәсе | 1857193,663 | IV | 21 | 39001 |
| 3 | Кабан дуңгызы | 1428073,13 | III | 10 | 14281 |
| 4 | Соры куян | 4142331,3 | V | 10 | 41423 |
| 5 | Ак куян | 1366791,295 | IV | 40 | 54672 |
| 6 | Суер | 1299949,31 | V | 10 | 12999 |
| 7 | Көртлек | 1799598,503 | III | 130 | 233948 |
| 8 | Соры урман тавыгы | 4142331,3 | V | 45 | 186405 |
| 9 | Су киек кошлары | 155140,9056 | III | 700 | 108599 |

98 нчы таблица

Татарстан Республикасында хуҗалык өчен максатка ярашлы аучылык хайваннарының төп төрләре баш санын исәпләү

| Т/с | Аучылык ресурсларының төп төрләре | Яшәү тирәлеге мәйданы, га | Бонитет | 1000 га максатка ярашлы баш саны | Татарстан Республикасының барлык территориясендә хуҗалык өчен максатка ярашлы баш саны |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Поши | 1366791,295 | IV | 3 | 4100 |
| 2 | Кыр кәҗәсе | 1857193,663 | IV | 15 | 27858 |
| 3 | Кабан дуңгызы | 1428073,13 | III | 8 | 11424 |
| 4 | Соры куян | 4142331,3 | V | 5 | 20712 |
| 5 | Ак куян | 1366791,295 | IV | 25 | 34170 |
| 6 | Суер | 1299949,31 | V | 5 | 6500 |
| 7 | Көртлек | 1799598,503 | III | 100 | 179960 |
| 8 | Соры урман тавыгы | 4142331,3 | V | 22 | 91131 |
| 9 | Су киек кошлары | 155140,9056 | III | 500 | 77570 |

Хайваннарның баш саны шкаласын исәпләү өчен аучылык биләмәләрендә конкурент төрләрнең (поши, кыр кәҗәсе) бары тик берсенең генә яшәве шарт булып тора. Аучылык биләмәләрендә ике яки өч конкурент төр яшәсә, хайваннарның хуҗалык өчен максатка ярашлы баш саны «кыр кәҗәсе берәмлекләре»ндә исәпләп чыгарыла. Конкурент төрләр өчен хуҗалык өчен максатка ярашлы баш санын болай исәпләп чыгарырга була: бер пошига сигез кыр кәҗәсе туры килә. Болай санауның җайлылыгы шунда ки, кирәк булганда әлеге төрләрнең теләсә кайсына өстенлек бирергә була.

2012–2013 елларда хуҗалык өчен максатка ярашлы булган һәр төр өчен исәпләп чыгарылган (оптималь) баш санын аучылык ресурсларының факттагы баш саны белән чагыштырганда (99 нчы таблица) төп аучылык ресурслары төрләре өчен «факттагы – оптималь баш саны» нисбәтен карарга мөмкин.

99 нчы таблица

Хуҗалык өчен максатка ярашлы һәм факттагы баш саннарының чагыштырма анализы

| Т/с | Аучылык ресурсларының төп төрләре | Баш саны күрсәткечләре (баш саны) | | Хуҗалык өчен максатка ярашлы баш санының факттагы баш санына процентларда нисбәте (%) |
|---|---|---|---|---|
| | | факттагы | хуҗалык өчен максатка ярашлы | |
| 1 | Поши | 8347 | 4100 | 204 |
| 2 | Кыр кәҗәсе | 1762 | 27858 | 6 |
| 3 | Кабан дуңгызы | 7168 | 11424 | 63 |
| 4 | Соры куян | 25247 | 20712 | 122 |
| 5 | Ак куян | 11012 | 34170 | 32 |
| 6 | Суер | 3276 | 6500 | 50,4 |
| 7 | Көртлек | 58296 | 179960 | 32 |
| 8 | Соры урман тавыгы | 68348 | 91131 | 75 |
| 9 | Киек су кошлары | 78113 | 77570 | 100,7 |

Татарстан Республикасы аучылык ресурсларының хуҗалык өчен максатка ярашлы һәм факттагы баш санын анализлау шуны күрсәтә: исәпләү мәгълүматлары буенча кыр кәҗәсе, ак куян, соры куян, кабан дуңгызы, суер, көртлек, соры урман тавыгы кебек төрләрнең аучылык биләмәләрендәге баш саны хуҗалык өчен ярашлы баш саныннан күпкә кимрәк.

Биләмәләрне браконерьлардан саклауның нәтиҗәлелеген арттыру, киек хайваннар запасын дөрес (рациональ) файдалану, аучылык хуҗалыгына зыян китерүче хайваннарның баш санын киметү буенча эшне оештыру, проектланучы биотехник чараларны тулы күләмдә башкару – болар барысы да аучылык биләмәләренең төп аучылык төрләренең хуҗалык өчен максатка ярашлы баш саны күрсәткечләренең факттагы баш саны күрсәткечләренә туры килүен булдыру өчен кирәкле шарт булып тора. Оптималь баш санын исәпләү дәрәҗәсеннән факттагы

баш санының артык булуы поши, ак куян өчен хас. Бары тик киек су кошларының биләмәләрдәге факттагы баш саны хуҗалык өчен максатка ярашлы баш санына туры килә.

## 7.5. Аларга карата ау лимиты билгеләнмәгән аучылык ресурсларының рөхсәт ителгән ау нормалары

«Ау турында» Законның 38 статьясының беренче өлеше нигезендә аучылык ресурсларын аларның баш санын яңарту өчен кирәкле булган чикләрдә тоту аучылык ресурсларын аулау һәм саклау өлкәсендәге нормативларны һәм нормаларны эшләү һәм үтәү юлы белән гамәлгә ашырыла.

«Ау турында» Законның 38 статьясының биш өлеше буенча аучылык ресурсларын аулау һәм саклау өлкәсендәге нормаларны, шул исәптән аучылык ресурсларының мөмкин булган ау нормаларын эшләү Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органнары компетенциясенә кертелгән.

«Ау турында» Законның 24 статьясы буенча аучылык ресурсларының аерым төрләрен аулау күләме (ау лимиты) аучылык ресурсларын аулау нормативлар нигезендә исәпләп чыгарыла. Әлеге статьяның 12 өлеше белән аларга карата ау лимит расланмый торган аучылык ресурсларын аулау аучылык һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендәге нормативлар һәм нормалар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Димәк, ау лимитлары нигезендә аулана торган аучылык ресурсларын аулауның нормаларын билгеләү аларга карата ау лимиты нигезендә аулау нормалары белән җайга салына, ә аларга карата ау лимиты билгеләнмәгән аучылык ресурсларын аулау рөхсәт ителгән ау нормалары нигезендә җайга сала.

Аучылык ресурсларын аулау нормативлары Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 2020 елның 25 ноябрендәге 965 номерлы карары, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 24 декабрендәге «Ау лимиты билгеләнми торган аучылык ресурсларын аулау нормаларын һәм Татарстан Республикасы аучылык биләмәләренең ау мөмкинлеге нормаларын раслау турында» 1119 номерлы карары нигезендә расланды.

Ау лимиты билгеләнми торган аучылык ресурсларын аулауның рөхсәт ителгән нормативы бары тик түбәндәге төрләр (төр төркемнәре) өчен генә билгеләнгән: себер бурсыгы, сусар, сасы көзән, кыргый мәче, кондыз, байбак, тау күркәсе, кабан дуңгызы. Татарстан Республикасы территориясендә әлеге төрләрдән себер бурсыгы, дала байбагы, елга кондызы, урман сусары һәм кабан дуңгызы яши.

Шул рәвешле, Татарстан Республикасында ау лимиты билгеләнми генә аулана торган аучылык ресурслары арасыннан бары тик шушы төрләр өчен генә рөхсәт ителгән ау нормативлары эшләнгән.

100 нче таблица

Татарстан Республикасы өчен ау лимиты билгеләнми торган аучылык ресурсларына ау нормалары (Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 2020 елның 25 ноябрендәге 965 номерлы карары)

| Аучылык ресурсының атамасы | Рөхсәт ителгән ау нормасы, аучылык ресурсларына һәм аларның яшәү тирәлегенә дәүләт мониторингы күрсәткечләре буенча агымдагы елның 1 апреленә хайваннарның баш санынннан % |
|---|---|
| Себер бурсыгы | 10 га кадәр |
| Дала байбагы | 40 ка кадәр |
| Урман сусары | 35 кә кадәр |
| Елга кондызы | 50 гә кадәр |
| Кабан дуңгызы | 80 гә кадәр |

Аларга карата ау лимиты каралмаган аучылык ресурслары өчен рөхсәт ителгән ау нормалары билгеләнми.

101 нче таблица

Татарстан Республикасында аучылык ресурсларын аулауның көндезге вакытта рөхсәт ителгән чик нормалары

| Хайван төренең атамасы, төрләр төркеме | Бирелгән бер рөхсәт кәгазе буенча сезон дәвамында ау нормасы, баш саны | Бер көнгә ау нормасы, баш саны | Аучылык биләмәләре буенча сезон дәвамында рөхсәт ителгән ауның чик нормалары (күләмнәре) (баш санынннан % ларда) |
|---|---|---|---|
| Елга кондызы | 10 нан да артык түгел | 1 дән дә артык түгел | 50 |
| Урман сусары | 4 тән дә артык түгел | 1 дән дә артык түгел | 35 |
| Америка чәшкесе | 8 дән дә артык түгел | 1 дән дә артык түгел | 50 |
| Су күсесе | 40 тан да артык түгел | 5 тән дә артык түгел | 50 |
| Гади тиен | 15 тән дә артык түгел | 2 дән дә артык түгел | 30 |
| Байбак | 16 дан да артык түгел | 2 дән дә артык түгел | 40 |
| Урман (дала) көзәне | 5 тән дә артык түгел | 1 дән дә артык түгел | 50 |
| Ак куян | 3 тән дә артык түгел | 1 дән дә артык түгел | 50 |
| Соры куян | 3 тән дә артык түгел | 1 дән дә артык түгел | 50 |
| Гади бүре, гади төлке, карсак | Билгеләнми | Билгеләнми | 95 |
| Янутсыман эт | 2 дән дә артык түгел | 1 дән дә артык түгел | 50 |
| Божыр | 8 дән дә артык түгел | 1 дән дә артык түгел | 30 |

| Хайван төренең атамасы, төрләр төркеме | Бирелгән бер рөхсәт кәгазе буенча сезон дәвамында ау нормасы, баш саны | Бер көнгә ау нормасы, баш саны | Аучылык биләмәләре буенча сезон дәвамында рөхсәт ителгән ауның чик нормалары (күләмнәре) (баш санынннан % ларда) |
|---|---|---|---|
| Соры урман тавыгы | 50 дән дә артык түгел | 5 тән дә артык түгел | 40 |
| Гади суер | 2 дән дә артык түгел | 1 дән дә артык түгел | 5 |
| Гади көртлек | 20 дән дә артык түгел | 3 тән дә артык түгел | 20 |
| Киек кошлар (язгы ау чоры): | Билгеләнми | | |
| Каз | | 2 дән дә артык түгел | Билгеләнми |
| Ата үрдәк | | 3 тән дә артык түгел | Билгеләнми |
| Тәлләтәвеч | | 3 тән дә артык түгел | Билгеләнми |
| Киек кошлар (җәйге-көзге ау чоры): | Билгеләнми | | |
| Каз | | 1 дән дә артык түгел | Билгеләнми |
| Үрдәк | | 5 тән дә артык түгел | Билгеләнми |
| саз-болын, кыр | | 5 тән дә артык түгел | Билгеләнми |
| Тәлләтәвеч | | 3 тән дә артык түгел | Билгеләнми |

Таблицада күрсәтелмәгән, алар өчен ау лимиты каралмаган аучылык ресурслары өчен рөхсәт ителгән алу нормалары билгеләнми.

## 7.6. Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларын исәпкә алу буенча тәкъдимнәр

Татарстан Республикасы территориясендә «Ау турында»гы Закон таләпләре нигезендә аучылык ресурсларының баш санын исәпкә алу аучылык ресурсларына һәм аларның яшәү тирәлегенә дәүләт мониторингының бер өлеше булып тора.

Исәпкә алуның бурычы булып хайваннарның баш саны һәм аларның территорияләрдә урнашулары турында мәгълүматның җирле шартларда җитәрлек күләмдә төгәллеген тәэмин итүче ысуллар белән ачыклау тора.

Татарстан Республикасы шартларында хайваннарны кышкы маршруты вакытында исәпкә алу, авиаисәп, мәйданнарга куып кертү, тояклы хайваннарны туплану урыннарында баш санын исәпкә алу, кама һәм чәшке баш санын исәпкә алу, су күсесенең баш санын исәпкә алу, бүренең баш санын картага төшерү ысулы белән исәпкә алу, суерны гөрелдәү чорында исәпкә алу, көртлекне гөрелдәү чорында исәпкә алу, көзге чорда маршрут буйлап исәпкә алу, елга кондызын исәпкә алу, киек су кошларын исәпкә алу кебек ысуллар кулланылырга мөмкин.

102 нче таблица

Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларының баш санын исәпкә алу өчен кулланырга мөмкин булган ысуллары

| Т/с | Ысулның исеме | Аучылык ресурсларының төрләре | Үткәрү сроклары |
|---|---|---|---|
| 1 | Авиаисәп ысулы | Поши, кыр кәҗәсе | 5 гыйнвардан 10 февральгә кадәр |
| 2 | Кышкы маршруты вакытында исәпкә алу ысулы | Поши, кыр кәҗәсе, кабан дуңгызы, селәүсен, бүре, төлке, карсак, себер бурсыгы, сусар, көзән, ләтчә, ас, тиен, куян, божыр, көртлек, суер, соры урман тавыгы | 1 гыйнвардан 28(29) февральгә кадәр |
| 3 | Сынау мәйданчыкларына тавыш ярдәмендә куып кертеп исәпкә алу | Поши, кыр кәҗәсе, кабан дуңгызы, бүре, төлке, карсак, селәүсен, соры куян, ак куян | 1 гыйнвардан 28(29) февральгә кадәр |
| 4 | Тояклыларның баш саны исәбен өстәмә тукландыру мәйданнарында исәпкә алу ысулы | Кабан дуңгызы, кыр кәҗәсе | 20 февральдән 10 мартка кадәр |
| 5 | Пошиның баш санын аны махсус тавышлар ярдәмендә җәлеп итеп исәпкә алу | Поши | 20 августтан 30 августка кадәр |
| 6 | Кама һәм чәшкене сулыкларның яр буе линияләрендә исәпкә алу | Кама, чәшке | 5 см дан да ким булмаган кар катламы барлыкка килгәч |
| 7 | Су күселәрен куышлары һәм оялары буенча исәпкә алу | Су күсесе | май |
| 8 | Кондызны җирлекләре буенча исәпкә алу | Кондыз | сентябрь ахыры – октябрь |
| 9 | Ясалма ояларда тоту ысулы белән су күселәрен кәсеп алдыннан исәпкә алу (язгы чорда исәпкә алуга өстәмә) | Су күсесе | 1 сентябрьдән 30 сентябрьгә кадәр |
| 10 | Бүрене, селәүсенне картага төшерү ысулы | Бүре, селәүсен | 25 февральгә кадәр очраганда |

| Т/с | Ысулның исеме | Аучылык ресурсларының төрләре | Үткәрү сроклары |
|---|---|---|---|
| | белән исәпкә алу | | |
| 11 | Ояда яшәүче хайваннарны оялары буенча исәпкә алу | Төлке, янутсыман эт | 15 майдан 25 июньгә кадәр |
| 12 | Ояларын картага төшерү буенча бурсыкларның баш санын исәпкә алу | Бурсык | 1 сентябрьдән 15 ноябрьгә кадәр |
| 13 | Байбакны тәҗрибә мәйданчыкларында исәпкә алу | Дала байбагы | 1 июньнән 15 июньгә кадәр |
| 14 | Суерның баш санын гөрелдәвек чорында исәпкә алу | Суер | Конкрет елда һава торышының нинди булуына бәйле рәвештә. Гөрелдәвек чорының бетүе каен яфрак чыгарган чорга туры килә (чама белән 10 апрельдән 25 майга кадәр) |
| 15 | Көртлекнең баш санын гөрелдәү чорында исәпкә алу | Көртлек | Конкрет елда һава торышының нинди булуына бәйле рәвештә. Гөрелдәвек чорының бетүе каен яфрак чыгарган чорга туры килә (чама белән 10 апрельдән 25 майга кадәр) |
| 16 | Күзгә маршрут исәбен алу ысулы | Боҗыр, суер, көртлек, соры урман тавыгы | 15 июльдән 15 августка кадәр |
| 17 | Киек су кошларын исәпкә алу | Киек су кошлары | 1 июльдән 15 августка кадәр |

Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларын исәпкә алу эшен оештыру аучылык биләмәләрендә һәм аучылык байлыкларының яшәү тирәлеге булган башка территорияләрдә вәкаләтле дәүләт органы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсе башлыгы карары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларының баш санын исәпкә алуны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы зат һәм территориаль бүлекчәләрдә аучылык ресурсларын исәпкә алуны үткәрүгә җаваплы затлар билгеләнә. Беркетелгән аучылык биләмәләрендә исәпкә алу өчен җаваплы затлар аучылык белән шөгыльләнүче оешмалар җитәкчеләре тарафыннан билгеләнә.

---

Татарстан Республикасы территориясендә ачылык белемләрен урнаштыру, файдалану һәм саклау схемасына 1 нче кушымта

# Татарстан Республикасы территорияләре административ бүленеше карта-схемасы



Татарстан Республикасы территориясендә аучылык
[illegible]
схемасына 2 нче кушымта

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ АУЧЫЛЫК РЕСУРСЛАРЫНЫҢ ЯШӘҮ ТИРӘЛЕГЕ ЭЛЕМЕНТЛАРЫ КАРТА-СХЕМАСЫ

